АКЧА ТӘМЕ

Халыкның микрозаем белән кызыксынуы ник арта?

> 5

ХАТ ЭЗЕННӘН

Кәче авылында яхшы юл өмет итәләр

> 6

РӨСТӘМ ГАЙЗУЛЛИН:

«Актер һөнәреннән башканы белмим»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 124 (28897) | Җомга | 26 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАЙТУ

ТАТАР ТЕЛЕ МӘКТӘПТӘ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ ИТЕП ӨЙРӘТЕЛӘ БАШЛЫЙ, ТИК...

Яңа уку елыннан татар теле мәктәпләрдә дәүләт теле буларак укытылачак. Бу хакта мәгариф хезмәткәрләренең республика август киңәшмәсендә Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин әйткән иде. Әлеге дәресләр мәҗбүри булачакмы, әллә ихтыярымы? «ВТ» хәбәрчесе шушы һәм башка сорауларга ачыклык кертергә тырышты, туган тел укытучыларының, әти-әниләрнең мөнәсәбәтен белеште.

> 7

Ишетми калмагыз

Россия Президенты Владимир Путин Кораллы Көчләрдә штатны якынча 140 мең кешегә арттырган. Дәүләт башлыгының бу җәһәттән Указы хокукый мәгълүматлар рәсми интернет-порталына урнаштырылган. «Россия Кораллы көчләрен 2039758 кешегә, шул исәптән хәрби хезмәткәрләр санын 1150628гә җиткерергә», – диелгән документта.
Финанс министрлыгы Оборона министрлыгына штатны киңәйтү өчен кирәкле акча бүлеп бирәчәк. Указ киләсе елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстанда авыл хуҗалыгы ярминкәләре 10 сентябрьдә ачыла. Алар 24 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Премьер-министр Алексей Песошин тиешле боерыкка кул куйган. «Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары билгеләгән махсус урыннарда көндәлек кирәкле азык-төлек сату буенча атналык ярминкәләр үткәрү тәкъдимен кабул итәргә», – диелгән документта.
Министрлык һәм район хакимиятләре башлыклары авыл хуҗалыгы продукциясен ярминкә мәйданчыкларына китерүне тәэмин итәргә тиеш. Министрлар Кабинетының Ветеринария баш идарәсе белгечләре исә терлекчелек продукциясенең сыйфатына күз-колак булып торачак.

Республикада берничә атна буе көннәрнең эссе торуы, явым-төшемнең булмавы сәбәпле, хәтәр күренеш – «атмосферада корылык» күзәтелә.
Синоптиклар августка хас булмаган эсселек һәм корылыкны аз хәрәкәтчән циклон белән аңлата. Көн дәвамында һава +30…+32 градуска кадәр кыза, тәүлеклек уртача температура нормадан 7–8 градуска югары. Ялларда да һава торышында үзгәрешләр көтелми. Шимбә, якшәмбе – 27–28 августта көндез +29…+34, төнлә +10…+15 градус. Яңгыр юк.
Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразларына карaганда, киләсе атна башында – 29 августта термометрның терекөмеш баганасы шул ук +29…+34 градусны күрсәтәчәк. 30 августта да эссе булачак. Кайбер районнарда зарыгып көтелгән яңгыр яварга мөмкин.

Рязань өлкәсе урманнарында инде икенче атна янгыннар котыра. Ут төртүгә бәйле булырга мөмкин бу. Россия гадәттән тыш хәлләр министры Александр Куренков шулай дип белдергән. Аның әйтүенчә, бүген хәлләр авыр булып кала, әмма барысы да контрольдә. Хәзер өлкәдә җиде урында урман яна. Икесендә сүндерелгән.
Министр әйтүенчә, көннәрнең бик эссе торуы янгын сүндерүне катлауландыра. «Мәсәлән, кичә һава температурасы 35 градус иде. Кинәт җил чыгу сәбәпле, 5 тапкыр янгынның агачлар очына күчү куркынычы туды. Ә монысы – иң хәтәре. Авиация җәлеп итү, җир өстендә зур эшләр башкару нәтиҗәсендә бу хәл булмыйча калды», – дип аңлаткан ул. Куренков шулай ук МЧС хезмәткәрләренең янгын сүндерү генә түгел, бәлки әле урманнарга якын урнашкан Ольгино, Голованово һәм Деулино авылларын уттан саклауларын да искәрткән.

Районнарда ни хәлләр?

Тукай

Яңа бистәдә Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды. Бу – бөек татар шагыйре исемен йөртүче районда аңа куелган беренче һәйкәл. Ачылу тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Тукай районы башлыгы Фаил Камаев һәм Бөтендөнья татар конгрессының Чаллы бүлекчәсе рәисе Факил Сафин катнашты. Бистәдә «Уңайлы шәһәр мохите булдыру» программасы буенча – парк, республика программасы буенча җирле мәдәният йорты төзекләндерелде. Кунакларга чаңгы базасын да күрсәттеләр.
(Тукай районының рәсми сайты)

Зәй

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең тормыш иптәше Нәкыя ханым балалары, оныклары, туганнары нәсел тамырлары тоташкан Бигеш һәм Урта Баграж авылларында кунак булды. Аяз Гыйләҗевнең әти-әнисе укытучылар булган, аларны элек бер авылдан – икенчесенә, бер мәктәптән икенчесенә күчереп йөрткәннәр. Урта Баграждагы йорт – аларның беренче үз нигезләре. Хәзер әлеге йорт музей буларак эшли. Аяз Гыйләҗев Урта Баграж авылы халкына – керәшеннәргә гомер буе рәхмәтле булган. Бу аның әсәрләрендә ачык күренә. Шушы авыл кешеләрен, мондагы сукмакларны, чишмәләрне, тауны язучының китапларыннан җиңел танысың. Кунаклар Аяз Гыйләҗевнең әти-әниләре истәлегенә ташлар куелган чишмәгә төшеп, шифалы судан да авыз итте. Соңыннан авыл мәдәният йортында очрашу да узды.
(«Зәй офыклары»)

Азнакай

Татшуган авылында баянчылар, музыка сөючеләр татар җыр сәнгатенең легендасы, танылган баянчы Шәфгать Салихховны искә алу кичәсенә җыелдылар. Бәйрәмне мәрхүмнең дусты, авылдашы Илдар Гадиев оештырды. «Әлеге фестиваль ел саен танылган баянчы истәлегенә туган авылы Татшуганда Сабан туе мәйданында уздырыла. Быел Чаллы, Сарман, Бөгелмә һәм башка күрше төбәкләрдән тальянчы-баянчылар, инструменталь ансамбльләр, артистлар килгән иде», – диде Татшуган авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе Фәнзирә Арсланова.
(«Маяк»)

Түбән Кама

Шәһәрнең барлык мәктәпләре диярлек башлангыч сыйныфларны 5 көнлек уку атнасына күчерде. Уку программасы турында фикер алышканда, һәр мәктәпнең педагогик советы шундый карар кабул итте. Узган уку елы башыннан биш көнгә күчерелгән 17 мәктәпкә шәһәрнең тагын егерме мәктәбе кушылачак. Кама Аланының ике мәктәбе дә яңа расписаниегә күчте. Алты көнлек уку атнасы 7 һәм 21 нче мәктәпләрдә, шулай ук авыл мәктәпләрендә кала. «Без балалары узган ел биш көнлек уку атнасына күчкән ата-аналар арасында сораштыру уздырдык. Алар, мондый режим ярдәмендә балалар белән вакытны күбрәк уткәрә алдык, дип билгеләп үттеләр», – диде мәгариф идарәсе җитәкчесе Айдар Гарифуллин.
(e-nkama.ru)

ТУГРЫЛЫК ҮРНӘКЛӘРЕ

КАЗАН КРЕМЛЕНДӘ РЕСПУБЛИКАНЫҢ 48 ГАИЛӘСЕН ХӨРМӘТЛӘДЕЛӘР

tatarstan.ru

Мәхәббәтле һәм бәхетле парлар. Матур гадәткә тугры калып, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, хатыны Гөлсинә ханым белән, республикада яшәүче үрнәк гаиләләрне Казан Кремлендә кабул итте. Бәйрәмгә 48 гаилә чакырулы иде. Күпчелеге – итәк тутырып бала сөючеләр, иңне иңгә куеп, озак еллар нык гаилә булып яшәүчеләр.

Тантаналы чара Республика көне алдыннан оештырыла. 8 ел эчендә бу бәйрәмдә 400дән артык Татарстан гаиләсе катнашкан.

Татарстан Президенты искәрткәнчә, бу чарага укытучылар да, табиблар да, кыр уңганнары да, гомумән, төрле тармак вәкилләре чакырылган.

– Үзегезнең көндәлек хезмәтегез белән сез газиз Татарстаныбызны зурлыйсыз, социаль-икътисади үсешенә өлеш кертәсез, төп күрсәткечләре буенча илдә алдынгылыкны саклауда ярдәм итәсез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Чарага җыелган гаиләләр алдында чыгыш ясаганда, Рөстәм Миңнеханов иң элек махсус операциядә батырлык күрсәтеп, Россия Герое исеменә лаек булган якташларыбыз – Дамир Гыйлемханов (һәлак булганнан соң бүләкләнде), Раил Габдрахманов, Иван Додосовның әти-әниләрен сәламләде һәм рәхмәт сүзләрен җиткерде.

– Сез улларыгызны чын ватанпәрвәр итеп тәрбияләгәнсез, Ватанга тугрылыклы итеп үстергәнсез. Бөтен Татарстан халкы исеменнән рәхмәт җиткерәм, – диде республика Президенты.

Ул ассызыклаганча, тантанага җыелган гаиләләрнең шактые – күпбалалылар. «Сез – чын ата-ана, нык гаилә үрнәге. Гаилә һәрвакыт җәмгыятьнең асыл кыйммәтләрен саклаучы булды. Нәкъ менә гаиләдә бала хезмәт яратырга, игелекле булырга өйрәнә; милли гореф-гадәтләрне күңеленә кертә», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Шунысы да сөенечле: ел башыннан Татарстанда аерылышучылар саны кимү һәм гаилә коручылар санының артуы күзәтелә. «Бу исә республикабызның тату һәм бәхетле гаиләләр төбәге булуын дәлилли», – диде Президент.

Тантанада Татарстан Президенты Мамадыш районыннан 8 балалы Саматовлар гаиләсенә, 10ар бала тәрбияләгән Түбән Кама районыннан Михайловлар һәм Казаннан Белоусовлар гаиләләренә Татарстан Республикасының «Ата-ана батырлыгы» медальләрен тапшырды. «Сезне чын күңелдән якынлашып килүче төп дәүләт бәйрәме – Республика көне белән котлыйм! Кадерле дуслар! Һәр гаиләгә бәхет һәм иминлек телим. Гаиләләр нык булсын!» – диде Рөстәм Миңнеханов.

Теманың дәвамы 17 нче биттә >

ТАТАРСТАН ТӘҖРИБӘСЕ

Бердәмлек хакына берләшү. Дөньяның 20 иленнән һәм Россиянең 75 төбәгеннән килгән 1,5 меңләп кунак Казанда узган «Сообщество» форумында төрле мәдәният һәм диннәр арасындагы татулык турында сөйләште. Билгеле, форум программасында җәмгатьчелекне борчыган башка мәсьәләләр турында да фикер алыштылар, тәҗрибә уртаклаштылар.

Россия Иҗтимагый палатасының «Сообщество» форумы 24–25 август көннәрендә узды. Экспертлар, коммерциячел булмаган һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре, активистлар, гомумән, җәмгыятьтә барган вакыйгаларга битараф булмаучылар, хакимият органнары һәм бизнес вәкилләре – барысы бер урында очрашты. Форум кысасында барлыгы 45ләп мәйданчык эшләде. Һәм һәркемнең борчыган сорауларын, теләк-тәкъдимнәрен җиткерү, уртак проблемалар турында уртага салып сөйләшү өчен мөмкинлеге бар иде. Форумның пленар утырышында Президент Рөстәм Миңнеханов та әлеге чараны җәмгыять, бизнес һәм хакимият арасындагы элемтәне ныгыту мәйданы дип атады.

– Көчле дәүләтне җәмгатьчелекнең актив эшчәнлегеннән башка күз алдына китереп булмый. Форумның бай программасы Россиянең иң яхшы тәҗрибәләрен күрсәтү һәм фикер алышу өчен киң мөмкинлекләр тудырыр дип ышанам, – диде ул. – Күпләргә безнең тәҗрибә кызыклы булыр дип уйлыйм. Безнең күрсәтерлегебез һәм сөйләрлегебез бар. Татарстанның Иҗтимагый палатасы инде 15 елдан артык җәмгыять тормышын көйләүдә зур роль уйный. Барлык министрлыклар һәм муниципалитетлар каршында да иҗтимагый советлар эшли. Социаль юнәлештә эшли торган министрлыкларның бурычы һәм максатлары да җәмгатьчелек катнашында билгеләнә.

Казанда узган форумның төп темасы – «Россия: мәдәниятләрнең күптөрлелеге, гражданнарның бердәмлеге». Россия Иҗтимагый палатасы секретаре Лидия Михеева билгеләп узганча, аның нәкъ менә Татарстан җирендә узуы – очраклы хәл түгел.

– Татарстан инде күп гасырлар буе төрле мәдәниятләрне һәм традицияләрне берләштерә. Бердәмлек турында сөйләгәндә, Татарстаннан үрнәк алырлыгыбыз бар, – диде ул. – Россия округларында уза торган һәр форумның максаты – ел ахырында Мәскәүдәге йомгаклау форумында федераль хакимият вәкилләре белән борчыган мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү. Без бирегә әйтелгән барлык теләк-тәкъдимнәрне исәпкә алабыз.

Форумның күп кенә мәйданчыкларында коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм чаралары турында фикер алыштылар. Лидия Михеева сүзләренчә, бүген аларның халыкара хезмәттәшлеге турындагы сөйләшүләр аеруча актуаль. Аның бу сүзләре белән Казахстанның Гражданнар Альянсы президенты Бану Нургазиева да килеште.

– Коммерциячел булмаган оешма вәкилләре яки актив гражданнар бик күпне эшли ала. Алай гына да түгел, алар тормышның барлык өлкәләренә дә иң югары дәрәҗәдә йогынты ясый алырга сәләтле дип уйлыйм мин. Безгә бөтен дөнья белән хезмәттәшлек итәргә кирәк, – диде Казахстаннан килгән кунак.

Традиция буенча, форум Татарстандагы коммерциячел булмаган оешмаларының уңышлы социаль проектлары турында сөйли торган күргәзмә белән ачылды. «Казан Экспо»да узган әлеге чарада республикадагы социаль-мәдәни оешмалары эшенең мөһим яклары, кешеләргә ярдәм итү һәм бу эшчәнлекне алып баручы битараф булмаган кешеләр турында сөйләделәр.

Россия Иҗтимагый палатасының «Сообщество» форумы 2015 елдан бирле уздырыла. Быел ул Новосибирскида һәм Липецкида узды, шулай ук Петрозаводск шәһәрендә оештырылачак. Йомгаклау форумы ноябрь башында Мәскәүдә узачак.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ПРЕЗИДЕНТКА – БҮЛӘК

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Мәскәүгә эшлекле сәфәре барышында тышкы эшләр министры Сергей Лавров белән очрашты.

tatarstan.ru

Министр Рөстәм Миңнехановка ведомство бүләген – «Халыкара хезмәттәшлеккә керткән өлеш өчен» күкрәккә тагу билгесен тапшырды. Бүләк ике яклы хезмәттәшлекне үстерү, рус теле һәм мәдәниятен популярлаштыру, ватандашларыбызга ярдәм итү проектларын гамәлгә ашыру буенча министрлык белән уртак эшләр өчен бирелә.

Тышкы эшләр министры шулай ук Татарстанның, шәхсән Рөстәм Миңнехановның илләр арасындагы элемтәләрне ныгыту өчен күпне эшләвен, Россиянең тышкы сәяси активлыгына зур өлеш кертүен искәртте. «Беренче чиратта Сезнең җитәкчелектәге «Россия – Ислам дөньясы» стратегик фаразлау төркеме эшчәнлегенә кагыла бу. Халыкара хәлләрнең катлаулы булуына карамастан, бүген Стратегик күзаллау төркеменең нәтиҗәле эшләвендә Сезнең өлешегез зур», – диде министр.

Шуннан соң Татарстанның, Россия төбәкләреннән берсе буларак, халыкара партнерлар белән уртак проектларын тормышка ашыру мәсьәләләре каралды.

«БЕРДӘМ РОССИЯ» КӨНЕ

Мөслим районында «Бердәм Россия» партиясе көне узды. Белгеч-табиблар халыкны кабул итте, гаилә кыйммәтләрен ныгыту, районда интернет-сәүдәне үстерү мәсьәләләре буенча «түгәрәк өстәл»ләр, мөмкинлекләре чикләнгән балаларны һөнәр үзенчәлекләренә өйрәтүгә багышланган семинар үткәрелде. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин район партия активы белән очрашуда чарага йомгак ясады.

Дәүләт Советы Рәисе биргә килүгә, район хакимияте башлыгы Альберт Хуҗин белән Балалар сәнгать мәктәбендә һәм район үзәгендәге ишегалдында булды.

Фәрит Мөхәммәтшин сәнгать мәктәбендә партиянең «Мәктәпкә җыенырга булыш!» хәйрия акциясе кысасында аз керемле гаиләләрдән беренче сыйныфка баручы балаларга портфельләр тапшырды. Ә инде Тукай урамында төзекләндерелгән һәм яшелләндерелгән 3 нче йорт ишегалдында Мөслим авылы халкы белән очрашты. Республика парламенты җитәкчесе аларны яңартылган ишегаллары белән котлап, Президент программаларының нәтиҗәле булуын билгеләп үтте.

Мәдәният йортында районның партия активы җыелышы үткәрелде. Фәрит Мөхәммәтшин, очрашуны ачып, кешеләр ышанычын яулауның урыннарда партия оешмалары эшендә төп максат булуын билгеләп үтте. «Мөслим партия оешмасы эшчәнлеге белән танышу, проблемаларны бергәләшеп хәл итү өчен җыелдык, – диде ул. – Бүген үткәрелгән «түгәрәк өстәл»ләр, семинарлар һәм очрашуларның җирле партия оешмасына алга таба эшчәнлекнең төгәл планын төзү мөмкинлеге бирәчәгенә ышанам. «Бердәм Россия» республиканың икътисади үсеше һәм кешеләрнең иминлеге өчен җаваплылык тотып эшли. Райондагы уңышлар өчен дә, проблемалар өчен дә нәкъ менә сез җавап бирәсез».

Фәрит Мөхәммәтшин республиканың иҗтимагый тормышында актив катнашучылары, социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүләре өчен Мөслимдә яшәүчеләргә рәхмәт белдерде. «Ашлык уңышының мулдан җыеп алынуы көтелә. Район икътисадының башка тармакларында да эшләр әйбәт бара. Барысы да – сезнең хезмәт, туып-үскән җирегезгә тугрылык нәтиҗәсе бу. Республика җитәкчелеге авылны социаль яктан үстерүгә, салада яшәүчеләрнең тормышын яхшыртуга гаять зур игътибар бирә», – диде ул.

Соңыннан Дәүләт Советы Рәисе район хакимияте башлыгы Альберт Хуҗин белән Иске Карамалы авылына барып, махсус хәрби операциядә һәлак булган Илгиз Фәттахетдиновның әти-әнисенең хәлен белеште.

Җитәкләп йөрисе

Татарстанда үсмерләр арасында хокук бозу очраклары арткан. Аларның күпчелеген урлау, талау кебек кырын эшләр тәшкил итә. Саннар теленә күчерсәк, бер ел эчендә Татарстанда яшүсмерләр тарафыннан кылынган хокук бозу очраклары 1,5 процентка арткан.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының участок хезмәткәрләре һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләр эшчәнлеген оештыру идарәсе җитәкчесе урынбасары Лариса Осипова сүзләренә караганда, хәзерге вакытта республикада хокук бозган 3 меңләп үсмер исәптә тора. Быел барлыгы 332 үсмер кырын эштә тотылган. Узган ел андыйлар 387 кеше булган. «Алар арасында берьюлы берничә җинаять кылган үсмерләр бар. Бу саннардагы үзгәреш шуңа бәйле. Кайчак бала үзенең җинаять кылганын аңлап та бетерми, урлауны әйбер алу дип кенә кабул итә», – дип зарланды Лариса Осипова.

Полковник сүзләренә караганда, кыек юлга баскан үсмерләр вакытлыча тору үзәгенә урнаштырыла. «Биргә җинаять кылган, әмма балигълык яшенә җитмәгән балалар озатыла. Гаиләсеннән, якыннарыннан аерылгач, алар монда бик тиз җиргә төшә. Үзәктә профилактика эше алып барыла», – ди ул.

Лариса Осипова кыек юлга баскан үсмерләрне тәрбияләүгә һәркем үз өлешен кертә ала дигән фикердә. Моның өчен «җәмәгать тәрбиячесе» дигән статус алырга гына кирәк. «Бу институт ун елдан артык эшләп килә. Аерым игътибарга лаек үсмергә бер өлкән кеше беркетелә. Әмма бу кеше үсмерне дөрес юлдан алып барырлык, әйтик, ул берәр төрле оешма җитәкчесе, депутат, район, авыл җирлеге башлыгы яки ярдәмчесе булырга тиеш», – дип фикер йөртә полиция вәкиле.

Лариса Осипова берочтан үсмерләрне соңгы арада киң таралган афәт – электрон тәмәкеләрдән дә сакларга кирәклеген искәртте. Төгәл саннарны әйтә алмаса да, республикада әлеге афәттән вафат булган үсмерләр барлыгын да ассызыклады ул. «Үсмерләр электрон тәмәкенең сәламәтлек өчен ни дәрәҗәдә зыянлы икәнен тиешенчә аңлап бетерми. Дөрес, араларында сәламәт тормыш алып баручылары да шактый. Шулай да үсмерләрнең күбесе бүген электрон тәмәке белән агуланган», – ди ул.

Ата-аналар һәм балалардан юлларда да игътибарлы булу сорала. Ник дигәндә, август – сентябрь айларында юлларда балалар катнашындагы юл һәлакәтләре саны бермә-бер арта, дип кисәтә белгечләр. Татарстанның ЮХИДИ идарәсеннән хәбәр итүләренчә, быелның 7 аенда Татарстан юлларында 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 280 юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда 10 баланың гомере өзелгән.

Бу фаҗигаләрне кисәтү максатыннан, 22 августтан 11 сентябрьгә кадәр Татарстанда «Игътибар: балалар!» дип исемләнгән профилактик чара уздырыла. Аның кысасында балигъ булмаган балаларны транспорт чарасында йөртү, машина йөртүчеләрнең җәяүлеләргә өстенлек бирүе буенча юл кагыйдәләренең үтәлеше, шулай ук балигъ булмаганнар арасында юл һәлакәтләрен булдырмау максатында профилактик чаралар үткәрү планлаштырыла.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Биек тауның башларында...»

Бездә шушы сүзләр белән башланып киткән җырлар бихисап. Аларны балачактан ук тыңлап, авыл яшьләренә кушылып җырлап үстек. Кайбер куплетларның мәгънәсен дә аңлап бетерми идек. Мәсәлән, егетләр:

«Биек тауның башларында
Тәгәрәтәләр мичкә.
Сеңлем, җаным, билең нечкә,
Чыдар микән бер кичкә», –

дип җырлаганда, чәрелдек тавыш белән ах-ух иткән булабыз. Әмма кояш белән бергә торып, иртәнге караңгыга хәтле йә колхоз басуында, йә әй тирәсендә эшләүче ябык кына кызны күз алдына китерә идек. Күрәсең, бу кыз ишле гаиләдәндер, олы бала булганга күп эшне аңа башкарырга туры килгәндер дип уйлаганбыздыр.

Әмма яшь борынга ис тиз керә бит ул. Бераз үсә төшкәч, ни җырлаганны белеп җырлый башладык.

«Биек тауның башларында
Җил әйләндерә ташны.
Кемнәр чибәр, кемнәр гүзәл –
Шул әйләндерә башны», –

дип, кичке авыл урамнарын яңгыратканда, аерым бер кызны күз алдына китерә идек. Мәсәлән, үзем Шәмси Гөлфиясенең мине тавышымнан таныячагына һәм, иң матур саналган күлмәген киеп, кич клубка чыгасына ышана идем. Әлбәттә, Гөлфиянең сайлап киярлек күлмәкләре булмагандыр да инде, югыйсә өстендә һәрвакыт бер күлмәк – сарыга кара борчак төшерелгәне булмас иде. Аның каравы шушы күлмәк аны дистәләгән кыз арасыннан аерып күрсәтә иде. Җәйге айлы кичләрдә авылның икенче башыннан танып була иде Шәмси Гөлфиясен.

Яшь барган саен, башка нинди генә уйлар керми икән, әй! «Биек тауның башларында...» – дип җырлауларын ишетүгә, күңел әсәрләнеп китә бит, малай! Болай әсәрләнү иң әүвәл яшьлек, мәхәббәткә бәйле, әлбәттә. Шул ук вакытта, татарның бөтен яшәеше биек тауларга бәйле кебек тоелып китә.

«Биек тауның башларында...» – дип, җыр сузып җибәрү башка бер халыкта да юк бугай ул. Булса, җырларлар иде. Татар исә, мәсәлән:

«Биек тауларның башында арысланнар оясы.
Арысландай егетләрне баса дөнья нужасы», –

дип сузып җибәрә дә гомеренең бер мизгелен көйгә сала да куя. «Биек тауның башларын» кырыкка төрләндерә ала татар һәм җырлаган һәр куплеты камил булып чыга. Мәсәлән,

«Биек тауның башларында
Утырып уйлар уйладым.
Утырып уйлар уйлар өчен
Үскән икән буйларым...» –

дигән сүзләрнең кай җиренә бәйләнәсең? Кайчак миңа татарны гомер буе җыр озатып бара кук тоелып китә. Авылны калдырып, калага юл тотканда, без: «Биек тауларга менгәч тә уңга киткән юл булыр. Исәр җилләр, чыгар кояш – бездән сәлам шул булыр», – дип җырладык. Әле: «Биек тауга менгән чакта, калды камчым каерылып. Калмады камчым каерылып, калды дуслар аерылып», – дип тә сузганбыз икән.

Мин бүген дә җырлыйм. Эштә дә җырлап йөрим. Мине белмәгәннәр моңа бераз сәерсенеп карый. Ә белгәннәр исә җырламасам сәерсенәләр. Җырлау – минем яшәү рәвешем. Чөнки мин – татар баласы, җырлы-моңлы халыкның бер вәкиле. «Биек тауның башларында» дип җыр башлавым да табигый. Без – үткәнен барлап, алга – югарыга карап яшәргә омтылган халык. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Һәрхәлдә, татарның «Биек тауның төпләрендә...» дип җырлаганын ишеткәнем юк әле. Ә менә: «Биек тауның башларында уйный төлке баласы. Җырлыйк-биик, уйныйк-көлик, дөнья бездән каласы», – дип шаяртып көйләп куярга күңел кытыкланып кына тора.

КҮҢЕЛЕМ ҮЗЕМ БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘ

Без көн саен икътисад фронтыннан әле инфляция, әле дефляция турында хәбәрләр алып торабыз, планетаның төрле почмакларында азык-төлек бәяләренең кушаяклап сикерүе, халыкларның ризасызлыгы хакында киң мәгълүмат белән танышабыз. Көнбатышта газга бәяләр югары булу сәбәпле, предприятиеләр ябылуы сөендерә безне. Ватанпәрвәрлек хисе тантана итә.

Әле менә соңгы көннәрдә генә Иминлек советы секретаре Патрушев әфәнде, күз күреме ераклыкта АКШның дефолт игълан итәчәген әйтеп, йөрәкләр буйлап җылы кан куды. Россиядә өченче ай рәттән дефляция бара, монысы да бавырларга кадәр төшеп сөендерә. Әмма бер нәрсә сагайта: вакыйгаларга бәя биргәндә, без сукырларның филгә бәя бирүен кабатлыйбыз, бөтенне күрмибез, өлешләрне генә капшап карыйбыз. «Фил бауга охшаган, фил – юан бүрәнә» дигән иллюзияләр шулай туа. Койрыгын гына капшап карасаң, синең күзаллауда фил – чынлап та, нәзек бау инде ул.

Бу язмага «Телеграм»га килгән бер хәбәр этәргеч бирде. Аны «СовЭкон» дигән агентлык тарата. 2022 елның июль – август айларында Россиядән бодай экспортлау 5,9 миллион тонна гына булган. Бу – соңгы еллардагы минималь күрсәткеч. Глобаль корылык һәм азык-төлек кытлыгы шартларында чит илләрдә Россия бодаен алырга атлыгып тормыйлар, чөнки бәясе Европа берлегендәгегә караганда кыйммәтрәк, диләр агентлыкта. Бодай кыйммәтрәк булгач, ипи дә бездә кыйммәтрәк булып чыга бит инде, шайтан алгыры. Болай үзе ипи Германия супермаркетларында Ташкичү кибетендәгегә караганда кыйммәтрәк икән. Бер буханкасы 1–2 евро тора, диләр. Бу – Евросоюздагы иң кыйммәтле илләрнең берсе. Буханканың авырлыгы әйтелмәгән. Аннан соң Ташкичү кибетендә дә шундый сортлы ипиләр сатыла: тулагәндә артыңа утырасың. Евросоюздан чыккан Англиядә 500 граммлы буханка безнең акча белән 95 сум тора. Әмма алардагы минималь хезмәт хакы белән бу – пүчтәк бәя. 1645 фунтны рубльнең курсына тапкырлыйк әле, 116 мең 400 сум чыга. Бу – британнарның айлык минималь хезмәт хакы. Уртачасы 180 меңнән артык. Бу акчага сызланмыйча гына ипи дә, килосы 790 сум торган ит тә сатып алып була инде. Әнә полякларның минималь хезмәт хаклары 37 мең сумга тулып җитми. Әмма аларда ипинең зур буханкасы 37 сум гына (бездәгедән арзан!), сөт тә шул бәядән йөри (тагын бездәгедән арзан!), казылыкның килосы – 237 сум тирәсе. Минем калькулятор шулай күрсәтә. Аңлый торгансыздыр инде: ит тә аларда арзанрак.

Юк-юк, мин көнбатышлыларга кызыкмыйм. Ватанымны яратам, шунда яшәп калам. Бездә ит кыйммәт булса да (августның соңгы атнасында Тукай районында итнең килосы – 655 сум, Арчада – 432), аның бәясе төшә. Ит җитештерүчеләрнең берсе буларак, ит дефляциясе мине сөендерми, билгеле, әмма аз керемле ватандашлар өчен шатланам. Бездә бит федераль МРОТ – минималь хезмәт хакы яңа гына үсә дә, полякларныкының 41 процентын гына тәшкил итә. Мине башка бер нәрсә борчый: дефляция дигәнебез черки томшыгы кадәр генә: нуль бөтен йөздән ничәдер процент. Шуның турында тау кадәр итеп шаулыйбыз. Менә августның 17сенә караган атнада сыер итенең бәясе Татарстанда 0,56 процентка очсызланган, сарык ите 0,96 процентка кыйммәтләнгән, дуңгызныкы 1,05 процентка арткан. Тавык ите 18 тиенгә арзанайган. Безнең акча янчыгы да сизми ул тиеннәрне. Кыйммәтләнгән продуктлар бар, шулай да арзанайганнары күбрәк. Дөге, мәсәлән, ике тиен хак югалткан. Хәзер аның килосы 106 сум 66 тиен йөри. Иң кыйммәтле дөге – Әлмәт районында, 123 сум 71 тиен. Әлмәт дөгесе Бөекбританиядәге уртача дөге бәясен 13 сум 71 тиенгә узып киткән.

Безнең финанс хакимиятләре күзгә кырып салырлык та булмаган дефляция өчен борчылалар, бәяләр төшүне туктатуның икътисади механизмнарын хәрәкәткә китерергә җыеналар. Өч ай рәттән бара торган дефляция һәм моның икътисад өчен хәвефле булуы турында бөтен үткәләр хәбәр итә. Ә бармы соң әле ул дефляция? Әйдәгез, бәяләрне чагыштырып, нәтиҗә ясыйбыз. Бер ел элек – 26 августта Татарстанда уртача бәяләр ничегрәк булган? Сыер итенең килосы – 375 сум 67 тиен. Хәзер – 481 сум 42 тиен. Көнбагыш мае – 121,15. Хәзер – 135,34. Шикәр – 52,54. Хәзер – 72,97 (!!!). Арыш ипие (килосы) – 51,53. Хәзер – 60,36... Исемлекне дәвам иттермибез. Еллыкка кучереп караганда, дефляция түгел, бөлдергеч инфляция күзәтелә. Еллыкка түгел, яртыеллыкка күчерсәк тә, без барыбер февральгә караганда хәзер күпкә югарырак бәяләрдән интегүебезне күрәбез. 25 февральдә сыер ите кыйммәтләнгән һәм 416 сум 57 тиенгә җиткән, әйтик. Хәзер 481 сумнан артыграк тора. Шикәр февраль ахырында (әле паника башланырга берничә көн бар) – 59 сум 63 тиен. Хәзерге 73 сум торган шикәр бәясен һич югында февральгә кайтарып, шуннан да түбәнәя башласа гына, дефляция дип чаң кагарга кирәктер ул, минемчә.

vk.com

Бу – дилетант фикере, билгеле. Менә шул дилетант глобаль икътисадта барган хәлләргә дә башкачарак бәя бирә. Мәсәлән, Словакиядәге Slovalco алюминий заводының, энергия чыганакларына бәяләрнең чамасыз югары булуы сәбәпле, җитештерүне туктатуы турындагы хәбәрне укыгач та, эчемдәге кыргый патриот кул чаба: «Бетсеннәр, кадалсыннар, безгә санкцияләр кертүнең ачы җимешләрен тұйганчы татысыннар», – ди. Дус булмаган илләрнең берсе бит инде. Башка дус булмаган илләрдә дә шул ук хәл: металл җитештерүче заводлар ишеккә йозак эләргә җыена, кешеләр эшсез кала. «Патриот»ның шул тантанасына дилетант каршы төшә: «Тукта әле, – ди. – Алкышлар вакыты түгел бу. Европадагы энергияне мул тотучы заводлар ябылса, нәрсә булачак, беләсеңме? Төп энергия чыганакларына – газга, нефтькә, ташкүмергә бәяләр төшәчәк. Аларга ихтыяҗ бетәчәк. Ә Россиянең төп кереме нәрсәдән?» Менә шул шул. Дилетантның бу фикере миңа «патриот» тантанасына караганда якынрак. Глобаль кризисның гөрелтесе башланса, бездә хәлләр тагын да начараячак бит. Бу юлы, чынлап та, зур кризисның «җимеше» АКШ дефолты булырга мөмкин. Әмма, бердән, ул дефолтка кадәр әле берничә ел бардыр, мөгаен. Икенчедән, аларның әҗәт түләүдән баш тартулары глобаль хаос китереп чыгарачак. Берәүгә дә җиңел булмаячак. Ковидка караганда берничә тапкыр көчлерәк китереп сугачак барыбызга да.

Хәзергә исә АКШ та, Евросоюз да егылырга бик ашыкмыйлар әле. Киресенчә, безне егарга, салып таптарга җыеналар. Бу атна башында гына АКШның финанс министры урынбасары Уолли Адеймо төрек финансчыларына кисәтүле хат юллады. Ул хатта Россия белән хезмәттәшлек иткән төрек банкларына ультиматум куелды. Адеймо: «Төрек банклары бер үк вакытта Россия банклары белән дә, Америка банклары белән дә корреспондентлык хезмәттәшлеге итә алмыйлар, икесенең берсен сайлагыз: я без, я Россия», – ди. Ничек уйлыйсыз: төрекләр кемне сайлаячак?

Кытай белән дә шул ук хәл. Кытай компартиясе сәясәтне АКШ һәм Япония белән араларны җылыту ягына таба борырга җыена. «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе кичә генә Япониядән шундый хәбәр алды. Япон премьеры Фумио Кисиде соңгы көннәрдә коронавирус белән чирләп ята. 22 августта Си Цзиньпин, Кисидега тизрәк савыгуын теләп, бик җылы эчтәлекле телеграмма юллады. Аналитиклар аның эчтәлеген «гадәттән тыш җылы» дип бәяләделәр. Андый телеграмма рәсми дәүләт документы дәрәҗәсендә йөри. Документта чиннарның японнар белән, яңа гасыр чынбарлыгын исәпкә алып, хезмәттәшлек итәргә теләүләре ассызыкланган. Әле кичә генә бу илләр үзара «дус булмаган илләр» булып санала, бер-берсенең чигe буенда мускуллар уйнаталар иде. Ничек уйлыйсыз: АКШ – Кытай, АКШ – Япония дуслыгы көчәю кемгә каршы булачак? Вашингтонда акрынлап Кытай һәм Һиндстанны да Россиягә арка белән бору сәясәте алып баралар. Яшереп тә тормыйлар. Безнең лидерлар исә хәзерге вазгыятьтә Көнбатыш башкалаларына да, Токиога да җылы эчтәлекле телеграммалар юллый алмый. Дилетант буларак, бу юллар авторы монда зур хәвеф күрә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

БУРЫЧ УПКЫНЫ

ӘҖӘТКӘ АКЧА АЛЫР АЛДЫННАН, АРТТЫРЫП КАЙТАРАСЫҢНЫ ДА УЙЛА

Соңгы арада Россиядә яшәүчеләрнең микрозаемнар белән кызыксынуы арткан. Июль аенда аның уртача күләме 9 мең сумны тәшкил иткән. Узган ай белән чагыштырганда ул азга гына – 0,2 процентка арткан, ди белгечләр. Кулланучылар кредитын бирү-алу да үсештә. Бу ике икътисади төшенчәнең бер үк вакытта җанланып китүе сагайтмый калмый, билгеле. Халык әҗәт камытын кия, димәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Саннар ни сөйли?

Уртача заем күләме буенча Татарстан 30 төбәк арасында бишенче урынны били. Өчлеккә Мәскәү (11440 сум), Ростов өлкәсе (10430 сум) һәм Санкт-Петербург (10050 сум) кергән. Татарстанда бу – 9912 сум. Әлеге саннарны Кредит тарихлары илкүләм бюросы китерә.

– Микрофинанс институтлары (микрофинанс оешмалары һәм кредит кулланучылар кооперативлары) китергән мәгълүматларга караганда, 2022 елның июлендә микрозаемның уртача күләме 9,04 мең сум тәшкил итте. Шул ук вакытта агымдагы елның июлен апрель ае белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 1,3 процентка кимегән. Апрель аенда заемның уртача күләме икътисади билгесезлек фонында бераз арткан иде – 9,16 мең. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, бу күрсәткеч 4,4 процентка арткан. 2021 елның июлендә ул 8,66 мең сум иде, – дип аңлата бюро белгечләре.

Бюроның маркетинг буенча директоры Алексей Волков сүзләренчә, банк бирә торган кредитлар белән дә шундый ук хәл күзәтелә. Май, июнь айларында алар үсештә булган.

Саннарга килсәк, июль аенда Татарстан халкы 33889 кредит алган. Июнь аенда исә – 29110. Июль аендагы кредитның уртача суммасы 265254 сумны тәшкил иткән. Гомумән, бу елның беренче яртысында, автокредитларны да исәпкә алып, республикада яшәүчеләргә 101 млрд сум кредит бирелгән.

Микрозаемнар базарының җанлануы һәм кулланучылар кредитын алучылар артуы хафаландыра, билгеле. Халык бурычка бата. Ил-көндәге вазгыять, чикләүләр матди яктан билгесезлек тудыра. Чөнки россиялеләрнең реаль хезмәт хакы еллык чагыштыруда 7,2 процентка кимегән. Бу – 2015 елның декабреннән исәпләгәндә, максималь кимү, дип раслый Росстат та.

Борчылыргамы?

Язмада күп тапкыр телгә алынган микрофинанс һәм микрокредит оешмаларының нидән гыйбарәт булуын аңлатып үтәргә дә кирәктер. Финанс белгече Ләйсән Харисова сүзләренчә, кредит алганда уза торган катлы-катлы тикшерүләр булмаганга күрә, микрофинанс оешмаларын халык үз итә дә инде.

– Микрофинанс оешмалары кешеләргә яисә оешмаларга әҗәткә акча биреп торучы оешма санала. Алар ике төргә бүленә. Беренчесе – микрофинанс компанияләре (МФК. – **Авт.**). Күп очракта бу – федераль әһәмияткә ия булган оешмалар. Икенчесе – микрокредит оешмалары (МКК. – **Авт.**), – дип аңлатты Ләйсән Харисова. – МФКга карата таләпләр зуррак. Алар аудит-тикшерү узарга, Үзәк банкка еллык хисап тапшырырга тиеш. Ә МККга андый таләпләр юк. Тагын аермаларына килсәк, МФКны Үзәк банк күзәтү астында тота. МКК өчен бу кайбер очракларда гына каралган.

> Иң аянычы да шул: мондый оешмаларга мөрәҗәгать итүчеләр дә – төрле катлау кешеләре. Әйтик, хәмер белән дус булганнар да, эшсез калганнар да... Тиз һәм җиңел бирелгән акчаны тиз һәм вакытында кайтарырга кирәк икәнен күпләр истән чыгара шул.

– Иң куркынычы – югары процент күрсәткечләре. Әнә шул процентлар аркасында, күпләр тиешле вакытында кредитын яба алмый да инде. Акча алганда күпчелек моңа игътибар итми, чөнки акча тиз арада кирәк. Шуңа процентларга карап тормыйлар, – ди Ләйсән Харисова. – Ә бит оешмадан алган сумма белән процент суммасын чагыштырсаң, икенчесе бик югары булырга мөмкин. Тагын бер куркыныч ягы: микрофинанс оешмаларының коллекторларга мөрәҗәгать итүе. Аларның нинди басым, ысуллар белән эшләгәнен чамалыйсыздыр.

«На балансе» бухгалтерия фирмасы җитәкчесе Гаяне Мөхәммәтҗанова халыкның микрозаемнар белән кызыксынуы артуының берничә сәбәбен күрә.

– Гомумән алганда, илебездә микрозаемнарга ихтыяҗ арту Россия банкының төп ставкасының кискен артуына бәйле. Бу хәл кулланучылар кредитларын банклардан алу мөмкинлеген киметте. Микрозаем үсешенең икенче сәбәбе – бар нәрсәнең дә кыйммәтләнүе. Төп ставка норма күрсәткеченә кайткач та, халыкның кереме бәяләр белән чагыштырганда артмады, – ди белгеч.

Гаяне Мөхәммәтҗанова микрозаем алучыларга киңәшләрен дә бирде.

– Гомумән, иң яхшысы – аны бөтенләй алмаска, – ди ул. – Бары тик котылгысыз хәл булганда гына кредит бирүнең әлеге ысулын карарга кирәк. Ни өченме? Чөнки бу – бик кыска вакытка бирелгән коточкыч процентлар, икенче төрле әйткәндә, бу – әҗәт упкыны. Шулай да микрозаем алу бердәнбер юл икән, нишләргә соң? Әлбәттә, килешү шартларына игътибар итәргә. Аерым алганда, әгәр дә заем алучы төрле сәбәпләр аркасында (хезмәт хакын тоткарлыйлар, тормышта көтелмәгән берәр хәл килеп чыга) вакытында акча кертә алмый икән, аңа зур пеня язылырга тиеш түгел. Кредиторга бу хакта хәбәр итү, өлешләп түләү яисә реструктуризация сорау мөмкинлеге булырга тиеш.

Сүз уңаеннан, хәзерге вазгыятьтә кредитоманнар да активлашты. Болар – кредит өстенә кредит алып, шул акчага яшәп, аннан физик затны банкротлыкка чыгару мөмкинлегеннән файдаланып, бурычларын юк итүчеләр. Гаяне Мөхәммәтҗанова әйтүенчә, һәр гамәл өчен җавап тотасы икәнен онытырга ярамый.

– Банкротлыкка чыгару процедурасы бер тапкыр уңышлы узды икән, икенче тапкыр инде алай булмаячак. Кредит тарихын бер мәртәбә бозгач, бер генә микрофинанс оешмасы да, банк та бурычка акча бирмәячәк. Болай уйнау сезгә кирәкме? Һәр кеше үзе хәл итә, – ди ул.

Икътисад фәннәре докторы, КФУның идарә итү, икътисад һәм финанс институты профессоры Игорь Кох сүзләренчә, кредит йөге үсә, ә халыкның керем дәрәҗәсе кими баруын исәпкә алып, әҗәтле вазгыять кискенләшергә дә мөмкин, әмма ул әлегә ни зур булмаячак. «Хәзерге көндә хөкүмәт тә икътисадка теләктәшлек итү юлында. Шул исәптән кулланучылар ихтыяҗы аша да. Шуңа күрә дә ул кредит бирү мөмкинлеген киңәйтәчәк кенә, чикләмәячәк. Инфляция күрсәткече кими, банкларда ирекле матди ресурслар бар», – дигән фикердә белгеч.

НИЧЕК АЛДАНМАСКА?

- Намуслы оешмалар мөрәҗәгать итүче кешене бурычка батыру максатын күздә тотмый. Вакытында түләмәгән очракта да, алар бурычны заем күләменнән 1,5 тапкырдан арттыра алмаячак. МФК процент, штраф һәм пеня исәпләүне туктатырга тиеш.
- Закон кысасында эшчәнлек алып барган оешмалар үзенең клиенты белән һәрвакыт әңгәмә корырга әзер.
- Мошенник саналганнарның максаты башка: алар чарасызлыктан мөрәҗәгать итүчеләрне бурыч упкынына кертергә генә тора. Бурыч хакын 10 мәртәбә арттыра да хәтта. Шәхси мәгълүматлар алдакчылар кулына эләгергә мөмкин.
- Оешма дәүләт реестрында теркәлгән булырга тиеш. МФК сайлаганда шуңа да игътибар итәргә кирәк.
- Килешү төзегәндә шартларны гына түгел, компания турындагы мәгълүматны да кат-кат тикшерегез. ОГРН, ИНН, теркәлү адресы, кыскартылма исеме – барысы да дөресме?
- МФК бик зур суммадагы акча бирергә дә әзер икән, бу шик уятырга тиеш. Закон буенча МФК – 1 млн сумга кадәр, МКК – 500 мең сумга кадәр акчаны бурычка биреп торырга хокуклы. Шәхси эшмәкәр яисә юридик зат заем буларак 5 млн сумга кадәр акча алырга мөмкин.
- МФКда инвестицияләр кертем булып саналмый һәм, билгеле, дәүләт тарафыннан якланмый да. Әгәр дә компания югары керем тәкъдим итә, кертем иминиятләштерелгән дип ышандыра икән, мошенниклар кулына эләгүегез бик мөмкин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БАТЫП ЙӨРИСЕ КИЛМИ

КӘЧЕ АВЫЛЫНДА ЯХШЫ ЮЛ ӨМЕТ ИТӘЛӘР

Редакциягә Арча районының Кәче авылыннан борчулы хат килеп иреште. Аны чыгышы белән шушы авылныкы, бүген исә Казанда яшәүче Рәфкать Ибраһимов язган иде. Хатта: «Авылда халык юлсызлыктан тилмерә. Тимер юл кичүеннән авыл башына кадәр бер чакрым арадагы юлның юл дип әйтерлеге юк. Казанга яки Арчага баручы машиналар, электричка тукталышына җәяүләп баручылар язын-көзен сазлыкка әйләнгән юлда интегеп йөрергә мәҗбүр. Авылны мескен хәлендә калдырып, юлсыз яшәтүне күңел кабул итми», – диелгән иде. Вазгыятьне үзебез күреп бәяләр өчен, юлга кузгалдык.

«Урам юлына таш түшәлде, инде хәзер Үзәк урамга асфальт көтәбез», – ди авыл халкы.

Юллар

Кәче авылы бик уңайлы җиргә урнашкан, чөнки Казанга да, Арчага да якын. Районда иң зур авылларның берсе дә әле ул. Бүген биредә 740 кеше яши. Мәктәбендә 71 укучы укыса, бакчасына 41 бала йөри. Клубы, бернича кибете, мәчете, чишмәләре бар. Авыл зур булгач, мәшәкатьләре, хәл итәсе мәсьәләләре дә байтак булып чыкты.

Рәфкать Ибраһимов, Казанда яшәү сәбәпле, юлларга кагылышлы соңгы яңалыклардан бик үк хәбәрдар булмаган, күрәсең. Соңгы 1,5–2 айда Сәйдәш, Күллек, Пионер урамнарына үзара салым акчасына вак таш түшәлгән. Үзара салым акчасы җитеп бетмәгәч, ярдәм кулы сузучылар да булган. Шуңа күрә авыл эчендәге юллардан зарланучы булмады. Без үзебез дә Пионер урамын барып күрдек. Чыннан да, юллары каралган иде.

– Юллар проблемасы – элек-электән килә торган мәсьәлә инде ул. Сүз дә юк, элек бик начар иде. Соңгы вакытта төрле программалар, үзара салым акчалары белән рәтләнеп килә үзе, – диде шушы урамда яшәүче Фиргать абый.

Марат Мөхәммәтҗанов та, бер ай элек кенә урамнарына таш түшәлгәч, хәлләр күпкә яхшырды, дип саный.

– Авыл советы башлыгы тырыша. Элек эре, уңайсыз таш түшәгәннәр иде. Хәзер вак таш (щебенка) салгач, юллар тигезләнде. Теге як урамнарга да салдылар. Аңа кадәр, чыннан да, юлларыбыз начар, бик пычрак була торган иде. Хәзер зарланып булмый, – диде ул.

Ә менә авыл башындагы Үзәк урам юлларын карарга кирәк. Коры көнне авырлыгы әллә ни сизелмәсә дә, яңгыр яуган вакытта халыкка шактый уңайсызлык китереп чыгарганын аңларга була иде. Авыл халкы да каткат искәртте бу турыда.

– Быел җәй ул юлга вак таш салдылар. Коры вакытта яхшы ул, ләкин яңгыр яуса, ашлык ташучы машиналар бозып та бетерергә мөмкин. Тимер юлның теге ягы да чокырлы-чакырлы. Машиналарга бик начар, – диде Марат Мөхәммәтҗанов.

Авыл советы башлыгы Руслан Гәрәев белән дә күрешеп сөйләштек. Аның әлеге вазыйфада эшләвенә алты гына ай икән әле. Шулай булуга карамастан, шактый эш башкарырга тырышканнар. Ә алда тагын да күбрәк эш көтә.

– Әйе, юллар проблемасы, чыннан да, бар, – диде ул. – Тимер юл ягыннан килә торган якынча 3 чакрым юл начар хәлдә. Быел анда таш җәйдек, ләкин алай гына булмый. Хәзер ул өлешкә асфальт җәйдереп булмас микән, дип тырышабыз. Сөйләшүләр бара. Ләкин быел гына була торган эш түгел ул. Бәлки, бер-ике ел узар әле.

Күпер

Безгә хат юллаган Рәфкать Ибраһимов халыкны борчыган тагын бер мәсьәләне күтәргән иде. Аның сүзләренчә, һәр ел язын Казансуның суы күтәрелеп, шактый мәйданны су баса. «Авыл аркылы Казансу елгасы ага. Аның да күпере бик начар, җитмәсә, язын бөтенләй су астында кала. Машиналы кешеләр транспортын авыл башында, кибет янында калдырып йөриләр. Бу да күңелне бик борчый», – дип язылган иде хатта.

Ташу суы булгән юлның бер ягында яшәүчеләр чишмәгә чыга алмыйча азаплангач, каршы якларның кибеткә юллары өзелгәч, асылмалы күпер ясап куйганнар. Су баскан вакытта җәяүлеләр шуннан йөри икән. Тик бу гына проблеманы хәл итеп бетерә алмый, билгеле. Руслан Гәрәев тә күпернең иң авыр мәсьәлә булуын әйтте.

– Күперне күтәртеп, яңадан эшләргә кирәк. Ә бу – шактый зур суммалар таләп итә торган эш. Мин килгәнче дә шактый йөргәннәр, әле дә төрле җирләргә хатлар юллыйбыз. Бер программага кереп булмас микән, дип йөрибез әле. Әлегә алдан әйтеп куйсак, дөрес үк булмас, – диде ул.

Руслан Гәрәев белән җәяүләп кенә чишмә, елга буйларын да карап мендек. Аны күргә, каршыбызга очраган һәр кеше үз гозерен әйтеп калырга тырышты.

> Кемгәдер баганадагы утны соң гына сүндереп, иртәрәк кабызырга кирәк, кайсындыр елгага ага торган пычрак су, кемнедер начар юллар борчый. Әйтерсең журналист килгәнне махсус көтеп торганнар. Кыскасы, авыл советы башлыгына эшләргә эш җитәрлек.

Күперне, юлларны каратасы, чишмәне төзекләндерәсе, үзәкләштерелгән су үткәрәсе бар. Әлегә болары – иң зурлары.

– Чишмәне карасыннар иде, – дигән теләген дә җиткерде Дилә Габдриева. – Аның улагы бик начар. Бар халык эчәргә шуннан су ала. Мин кер чайкарга да төшәм әле. Шуның улагын яңартып, ян-якларын буяп куярга кирәк иде.

Без дә барып күрдек чишмәне. Чыннан да, авылда үзәкләштерелгән су булмагач, бар халык суны шуннан ала. Хәтта күрше авылдан да килеп алып китүчеләр бар икән. Чишмә янынннан кеше өзелми, кыскасы. Ә улагын, дөрестән дә, яңартып, кырыйларын буяп куясы бар.

– Чишмәнең улагы турында да беләм. Карый да башладым. Аны ясар өчен, 45 сантиметрлы агач кирәк. Такта ярдыру цехы тотучы авылдашыбыз Айдар Закиров белән сөйләшеп карадык. Андый киңлектәге агач табу бик авыр. Без инде тар такталарны ябыштырып эшләп карарга булдык. Быел ул эшне башкарып чыгачакмын, – диде Руслан Гәрәев.

Болардан кала, Казансу елгасы суыннан да бик нык зарландылар. Чыннан да, елга янына якыная башлауга, борынга сасы ис килеп бәрелде. Суы да ак төстә. Соңгы елларда Арча, Балтач районнары елгалары өчен иң зур проблема шушы инде. Халык, елгага Арча сөт комбинаты пычрак су агыза, дисә дә, Руслан Гәрәев әйтүенчә, экологлар алып киткән анализлар бернинди дә нәтиҗә бирмәгән. Ягъни суда кимчелекләр табылмаган. Кыскасы, бу күренешнең сәбәбе әлегә кадәр ачыкланмаган.

Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Гатиятовка да мөрәҗәгать итеп, юл һәм күпер проблемаларының хәл ителеше белән кызыксындык.

– Кәче авылы турында беләбез, – диде ул. – Әлегә тимер юлга кадәргे өлешенә вак таш түшәдек. Киләчәктә тимер юлның икенче ягына асфальт салырга кирәк булачак, чөнки ул ватылып беткән. Киләсе елда шул өлешкә «Главтатдортранс» оешмасы программасы кереп, вак таш түшәргә исәплибез. Шуннан соң асфальт җәйдерү планы бар. Шулай ук авылның Әтнә юлына тоташа торган ягына асфальт салу һәм яңа күпер төзү планы да бар. Ләкин әлеге эшләрнең төгәл вакыты билгеле түгел.

«Безнең урам – иң яхшысы»

Гомумән алганда, авылның халкы шөкер итеп яши. Алар белән аралашкан вакытта, үзләрен борчып тора торган мәсьәләләрне күтәрсәләр дә, яхшылыклар турында да бик теләп сөйләделәр.

– Авылыбыз турында бер начар сүз дә әйтә алмыйм, – диде Әнисә Мөхәммәтшина. – Ә инде урамыбыз халкын мактап туя торган түгел. Безнең урам (сүз Пионер урамы турында бара. – **Авт.**) авылда бер. Без бик тату яшибез. Бай да түгелбез, хәерче дә тормыйбыз. Барыбыз да урта хәлле тормыш алып барабыз. Ачуланышуны, сүзгә килешүне, көнләшү-хөсетлекне гомумән белмибез. Әнә күршебез Назыйм абый, бал аерткач, шушы урамда яшәүче һәр гаиләгә өлеш чыгарды. Корьән ашларына чит кешене чакырасы да юк. Барысы да – үзебезнең урам кешеләре. Электән шундый булдык. Үзган ел коронавирустан бер-бер артлы ике ир-ат үлде. Бик авыр кичердек бу югалтуларны.

Аның сүзен Дилә Габдриева да куәтләде.

– Сөенечле хәл буламы, көенечлеме – барысы да уртак. Бер ел элек ирем үлеп китте. Кайгымны бергә күтәрдек. Күршеләремә елый-елый рәхмәт укыйм. Бер көн дә калмыйлар, кереп, хәлне белешеп торалар. Туганнарым үзләренә чакырган иде. «Бу кешеләрне калдырып, ничек китим? Нәрсә сөйлисез сез?» – дидем. Урамыбызга яңа гаиләләр дә кайтты. Алар да безнең төслегә әйләнеп бетте инде, – диде ул.

Урамның иң өлкән кешесе Асия апа да күршеләренең сүзләрен җөпләп куйды:

– Кияүләр үзләренә бик чакыра, ләкин минем беркая чыгып китәсем килми. Күршеләрем хәлемне белеп тора, нинди йомышым булса, алар йөгереп керә. Безнеке кебек урам башка бер генә җирдә дә юктыр.

Яшь җитәкче булса да, Руслан Гәрәев тә халык белән уртак тел табып эшләргә тырыша, дигән фикер калдырды.

– Авылның халкы ошый миңа. Күмәк, бердәм. Яшьләре актив, – диде ул. – Сабан туе, башка мәдәни һәм спорт чаралары уздырган вакытта аеруча күренде ул. Үзем дә халык белән аралашырга яратам, аларның сүзләрен тыңлап, булдыра алганча гозерләрен үтәргә тырышам. Дөрес, эш вакытында төрле хәлләр булгалый анысы. Ләкин аннан башка күңелсез дә булыр иде.

Сәрия
МИФТАХОВА

КАЙТУ

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– 2022 елның 1 сентябреннән республика мәктәпләренең уку планнарында «Татарстан Республикасы дәүләт теле – татар теле» фәне кертеләчәк. Баланы укыту әти-әниләрнең теләгенә бәйле булачак. Татар телен дәүләт теле һәм туган тел буларак укыту федераль реестрга кертелгән белем бирү һәм эш программалары буенча оештырылачак, – диде Илсур Һадиуллин.

Министр белдергәнчә, Татарстан Фәннәр академиясе, Мәгарифне үстерү институты белән берлектә татар теле һәм әдәбиятыннан яңа буын дәреслекләр эшләүне дәвам иттерә. Россия Мәгърифәт министрлыгы каршындагы Фәнни-методик совет карары белән 17 әсбап 2022 елда федераль исемлеккә кертелгән. Төп мәктәп өчен 18 әсбап экспертизага тапшырылган.

Икесе дә кирәкме?

Мәктәпләрдә татар теле дәресләре моңа кадәр дә бар иде. Аны туган тел рәвешендә татар гына түгел, рус, чуаш, удмурт баласы да укый ала. Шулай итәләр дә. Рус теле дә татар баласының «туган тел»енә әйләнгән очраклар бар. Укучыга шулай тәкъдим иткәч, нишләтәсең? Татар теле дәүләт теле буларак та кертелгәч, нәрсә үзгәрә соң? Ике дәресне дә сайлау мөмкинме?

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф бүлеге башлыгы Энҗе Гыйззәтуллина аңлатуынча, 1 сентябрьдән 1 һәм 5 нче сыйныфларга яңартылган стандартлар кертелә. Алдагы сыннан аермалы буларак, яңартылган стандартларда «Туган тел һәм туган тел әдәбияты» фәне өлкәсенә Россия Федерациясе республикасының дәүләт телен өйрәнү мөмкинлеге кертелгән. «Алдагы елларда әти-әниләр «Туган тел», «Туган тел әдәбияты» фәннәре кысасында өйрәнү өчен татар, рус, чуаш, удмурт, мари, мордва, яһүд телләрен сайлый алалар иде. Хәзер татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак сайлый һәм өйрәнә алачаклар. Шулай ук әти-әни гаризасы буенча. Сәгатьләр саны мәктәпнең уку планында билгеләнә, аны мәктәп үзе расләый», – дип белдерде белгеч.

Энҗе Гыйззәтуллина туган тел һәм әдәбиятын элек булганча, хәзер дә яңа стандартларда уку планының мәҗбүри өлешендә калуын әйтте. «Рус телен яки татар телен өйрәнү әти-әниләр гаризасы буенча хәл ителә. Әгәр татар телен сайлый икән, аны туган тел яки дәүләт теле буларак өйрәнүне үзләре сайлый. Әгәр мәктәп икесен дә уку планына кертә икән, бу вакытта икесен дә укый алалар. Ни өчен безгә бу мөһим иде? Татар телен белми торган башка милләт балаларының әти-әниләре: «Татар телен өйрәнәсе килә, тик ул безнең туган тел түгел, шуңа күрә аны туган тел буларак сайлый алмыйбыз, ә менә дәүләт теле буларак өйрәнер идек», – диделәр. Андыйлар күп иде, хәзер алар татар телен рәхәтләнеп дәүләт теле буларак сайлый алалар», – диде Энҗе Хәбир кызы.

Богдан татарча укый

Татар теле башка милләт балалары өчен дә чит түгел анысы. Әгәр әти-әнисе каршы булмаса... Бөгелмәнең лицей-интернатында белем алучы Богдан Кизим татар телен туган тел буларак өйрәнә. Быел ул 8 нче сыйныфка укырга бара.

– Татарстанда яшәгән һәр кеше татар телен белергә тиеш. Һич югында татарча әйткәнне аңларга. Без ирем белән шулай уйлыйбыз. Телләр белү бер нәрсәгә дә комачауламый. Балаларны бакчада татар төркеменә бирдек. Кызыбыз быел 4 нче сыйныфка бара. Алар мәктәптә дә татар телен туган тел буларак өйрәнә. Туган телне сайлау проблемасы булмады. Икеләнеп тормадык, һичшиксез, татар теле, дидек. Берниди басым да ясамадык, татар телен үзләре сайладылар. Без инде хупладык. Богдан татарча сөйләшә. Быел фестивальдә катнашкан иде, шунда төрки халыкларның тарихы турында ишеткән. Аннан кайткач, тарих белән кызыксына башлады, – ди әнисе Екатерина.

Директор милли җанлы булса...

Түбән Кама шәһәрендәге 35 нче лицей директоры Чулпан Хуҗанбердиеваның да фикерен сораштык.

– Без лицейга укучыларны 5 нче сыйныфка кабул итәбез. Быел 1 нче сыйныфка 125 бала кабул иттек. 10 нчы сыйныфка 100дән артык укучы килде. Профильле уку йорты булсак та, татар телен укыту бик югары дәрәҗәгә куелган. Мин үзем – татар теле укытучысы бит. Татар төркемнәренә балалар җыю проблемасы юк. Әти-әниләрнең 75 проценты туган тел буларак татар телен сайлый. Татар теле ике сәгать укытыла. Яңа уку елыннан дәүләт телен кертү 5 нче сыйныфка килүчеләргә сайлап алу мөмкинлеге бирәчәк, – диде ул.

Өстәмә мөмкинлек

«Татарстан Республикасының дәүләт теле – татар теле» яңа программасы авторларының берсе, «Ана теле» онлайн мәктәбе җитәкчесе, КФУ галимәсе Кадрия Фәтхуллова мәктәпләрдә татар телен дәүләт теле буларак укытуны уңай адым дип саный. Аның әйтүенчә, бу татар телен өйрәтү өчен балаларга өстәмә мөмкинлек бирә. Дәүләт телен укыту яңа программа нигезендә өч сәгать каралган. Кайбер мәктәпләр милли компонент хисабына сәгать санын арттыра да ала, ләкин монысын мәктәп хәл итә.

– Моңа кадәр татар телен, туган тел буларак, күбрәк татарлар сайлый иде. Әлбәттә, арада башка милләт балалары да бар. Хәзер татар телен башка милләт балалары да сайлый алачак. Алар: «Бу бит минем туган тел түгел», – димәячәк, – ди Кадрия Фәтхуллова. – Шунысы мөһим: туган тел булганда, укучылар туган тел һәм әдәбиятны өйрәнә. Ә менә дәүләт теле буларак, бары тел генә укытылачак. Төп максат – балаларны шушы телдә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү. Кайбер әти-әниләр әдәбиятны катлаулы дип саный. Башка милләт балалары дәүләт теле буларак сайлап ала икән, аларга уку җиңелрәк булачак. Ләкин шул ук татар балалары, туган тел буларак уку авыр дип, дәүләт телен укыту төркеменә күчмәсен иде, дигән теләк белдерә белгечләр. Дәреслекләргә килгәндә, яңа дәресләрне шул ук дәреслекләр белән дә укытырга мөмкин.

ФИКЕР

Ханә СӨЛӘЙМАНОВА,
Казандагы 149 нчы лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы:

– Сөенеп түгел, тагын нинди авырлыклар килер икән, дигән шомлану белән кабул итәм моны. Тел мәсьәләсендә һәр үзгәрешкә куркып карыйбыз инде хәзер. Югары сыйныфларда сәгатьләр саны кими, диделәр. Озак еллар укыткан укытучы буларак, мондый әйберләрне бик авыр кабул итәм. Әти-әниләр сайлауга калгач, юк инде ул. «Телим икән – өйрәнәм, теләмим икән – өйрәнмим», – дию белән расписаниедәге мәҗбүри фән икесе – ике нәрсә. Дәүләт теле булгач, ул шул дәүләттә яшәүчеләргә мәҗбүри куелырга тиеш. Ләкин һаман да әти-әниләр тарафыннан ничек кабул ителер дә ничек эшләп китәр? Анысы да бар бит әле. Әти-әниләр гариза язса – укытыла, язмаса – юк. Кайвакыт алар саф татарча сөйләшкән балаларын да рус төркеменә яздыралар. Нинди генә авыр заманалар булса да, телебез югалмаган. Ул сакланыр, милләтебез, телебез өстенә төшкән зур сынаудыр инде бу. Анысы да үтәр дип ышанам.

Рәмис МӨҖИПОВ,
Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе:

– Мәктәпләрдә туган телләрне укыту сәгатьләренең кыскаруына юл куярга ярамый. Ул һәр мәктәптә билгеләнгән күләмнән ким булмаска тиеш. Яңа уку елыннан 1 һәм 5 нче сыйныфларда яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартлары кертелә. Әлеге документның беренче вариантында уку сәгатьләре азрак иде. Республика, башка төбәкләр мөрәҗәгать иткәннән соң, Мәгърифәт министрлыгы туган тел дәресләрен узган уку елы күләменә кире кайтарды.

УЗГАН УКУ ЕЛЫНДА «ТУГАН ТЕЛ»НЕ САЙЛАУ КҮРСӘТКЕЧЕ:

289175 бала **(63,34%)** татар телен өйрәнгән.
161288 бала **(33,33%)** – рус телен
3860 бала **(0,85%)** – чуаш телен
1040 бала **(0,23%)** – удмурт телен
465 бала **(0,10%)** – мари телен
39 бала **(0,01%)** – мордва телен
694 бала **(0,15%)** – ивритны
8 бала – башкорт телен



29 август | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «БЕРЕНЧЕ ТЕАТР» 12+
10.00, 00.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.00 «Бердәм булыйк». Хәйруллин Гриф Тимерзаһитович 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Татарлар» 12+
16.30 Хоккей. Кубок чемпионов TANECO. «Ак барс» (Казань) – «Салават Юлаев» (Уфа). Прямая трансляция 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 12+
00.50 «Каравай». Башкирский национальный костюм 6+
01.15 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Илһам Шакиров турында телеочерк (субтитрлы) 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Яңалыклар» 12+
00.00 «Яңалыклар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Юлия Пересильд, Александр Устюгов, Сергей Пускепалис.«ЗОЛОТАЯ ОРДА» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «ГОДУНОВ» 16+
02.00 «МОРОЗОВА» 16+
03.45 «СРОЧНО В НОМЕР!» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 08.55, 12.30, 14.55, 20.10 Новости
06.05, 17.30, 19.35, 21.40 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «ВЫШИБАЛА» 16+
11.00 VII Армейские Международные игры «АрМИ – 2022». Танковый биатлон 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35, 03.10 Специальный репортаж 12+
12.55 «ВЗАПЕРТИ» 16+
15.00 «Громко». Прямой эфир
15.55 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Гандбол. Женщины. Финал. Прямая трансляция
17.55 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Гандбол. Мужчины. Финал. Прямая трансляция
20.15 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Церемония закрытия. Прямая трансляция из Москвы
22.30 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Финал. Прямая трансляция из Москвы
00.15 Тотальный футбол 12+
00.45 «Дом летающих кинжалов» 12+
03.05 Новости 0+
03.30 «Мэнни». Док. фильм 16+
05.15 «Громко» 12+

НТВ
05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.50 Остросюжетный сериал «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА» (S) 16+
21.50 «РИКОШЕТ» (S) 16+
00.10 «ПЁС» (S) 16+
02.10 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.45 «Порча». «Тяжкое бремя» 16+
13.15 «Знахарка» 16+
13.50 «Верну любимого» 16+
14.25 «Преступления страсти» 16+
18.45 «Скажи, подруга» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ НЕ КАРТОШКА». 1-я – 4-я серии 16+
22.45 «Порча». «Чужое имя» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.25 «Понять. Простить» 16+
01.20 «Тест на отцовство» 16+
03.00 «Давай разведёмся!» 16+
03.50 «Преступления страсти» 16+
04.40 «6 кадров» 16+
05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.20 «ИСЧЕЗНУВШИЕ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ВОЗВРАЩЕНИЕ «СВЯТОГО ЛУКИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.35 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.50, 14.05 «МАЙОР ПОЛИЦИИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Освободители». Док. сериал. «Бомба Озаричи». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Иван Утробин. Штирлиц из российской глубинки». Премьера! 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
01.20 «ЖАЖДА» 12+
02.35 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+
03.55 «МАЙОР ПОЛИЦИИ» 16+

30 август | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Бәйрәм чыгарылышы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» Праздничный выпуск 12+
09.00 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова 6+
11.00, 19.00, 20.00, 21.00 «Туган көнең белән, Республикам! С Днем рождения, Республика!» Прямая трансляция праздничных мероприятий 0+
15.00 «Мой Татарстан». Телефильм 12+
15.20 Э.Низамов, Р.Харис. «КАРА ПУЛАТ». Опера 12+
17.00 «Каравай». «Татарстан – многоцветие культур» 6+
18.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концертыннан турыдан-туры трансляция 0+
22.00 Праздничный салют 0+
22.05 «ВЕХИ ИСТОРИИ». Новый век Татарстана 6+
22.40 «ЦИРК» 16+
00.10 «Видеоспорт» 12+
00.35 «Соотечественники». Великие татары 12+
01.00 «Вехи истории». Татарская культура. Душа народа 6+
01.25 «Туган якка мәдхия». Концерт 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Манзара» 6+
08.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00 «Туган көнең белән, Республикам! С Днем рождения, Республика!» Бәйрәм чараларыннан турыдан-туры трансляция 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Туган якка мәдхия». Концерт 6+
17.30, 19.30, 00.40 «Татарлар» 12+
18.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концертыннан турыдан-туры трансляция 6+
18.30 «Яңалыклар» 12+
19.00, 20.00, 21.00 «Туган көнең белән, Республикам! С Днем рождения, Республика!» Бәйрәм чараларыннан турыдан-туры трансляция 6+
20.30 «Яңалыклар» 12+
21.30 Э.Низамов, Р.Харис. «КАРА ПУЛАТ». Опера 12+
23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
00.00 «Яңалыклар» 12+
00.15 «Ватандашлар» 6+
01.05 «Манзара» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «ГОДУНОВ» 16+
02.00 «МОРОЗОВА» 16+
03.45 «СРОЧНО В НОМЕР!» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 08.55, 12.35, 15.05, 18.00, 21.00 Новости
06.05, 15.10, 18.05, 21.05, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «ВЫШИБАЛА» 16+
11.00 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 Специальный репортаж 12+
13.00 «РАЗБОРКИ В СТИЛЕ КУНГ-ФУ» 16+
16.00 «РУСЛАН» 16+
18.55 Футбол. ФОНБЕТ Кубок России. Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Интер» – «Кремонезе». Прямая трансляция
00.30 «КРОВЬ И КОСТЬ» 16+
02.25 «Правила игры» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 «Голевая неделя» 0+
03.25 Футбол. Кубок Либертадорес. 1/2 финала. «Атлетико Паранаэнсе» (Бразилия) – «Палмейрас» (Бразилия). Прямая трансляция
05.30 «Наши иностранцы» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.50 Остросюжетный сериал «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА» (S) 16+
21.50 «РИКОШЕТ» (S) 16+
00.10 «ПЁС» (S) 16+
02.00 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить (ТК Домашний)» 16+
13.05 «Порча». «Тринадцать бед» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «Преступления страсти» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ – НЕ КАРТОШКА». 5-я – 8-я серии 16+
22.45 «Порча». «Мёртвая любовь» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.55 «Верну любимого» 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.25 «Тест на отцовство» 16+
03.05 «Давай разведёмся!» 16+
03.55 «Преступления страсти» 16+
04.45 «6 кадров» 16+
05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.25 «МАЙОР ПОЛИЦИИ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ЧЕРНЫЙ ПРИНЦ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.35 «Оружие Победы» 12+
13.50, 14.05 «МАЙОР ПОЛИЦИИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Освободители». Док. сериал. «Шталаг 352. Пленная правда». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Ученики Геббельса. Тайна кровавых фейков Украины». Премьера! 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
01.20 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ…» 12+
02.40 «ПОДКИДЫШ» 6+
03.50 «МАЙОР ПОЛИЦИИ» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ

«Татарстан Республикасында (Татарстанда) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Нурлат филиалы баш табибы **Әхмәтҗанов** Илдус Рифгать улына, «Дентиатр» медицина стоматология предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Әхмәтова** Диларә Мокатдис кызына, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең эндокринология кафедрасы мөдире **Ваһапова** Гөлнар Рифат кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының поликлиника часте буенча урынбасары **Жиденко** Елена Александровнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе башлыгының оештыру-методика эше буенча урынбасары – табибы – суд-медицина эксперты **Жолобов** Альберт Ивановичка, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең физиотерапия бүлекчәсе мөдире – табибы-физиотерапевты **Кучумова** Татьяна Витальевнага, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Медицина-санитария часте 2 нче хирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-хирургы **Минабетдинов** Рафаэль Минсәлим улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Иволга» санаторий-сәламәтләндерү комплексы баш табибы **Мөхәммәтшина** Римма Марсель кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Нәҗметдинова** Эльмира Дилүс кызына, «Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табиб-рефлексотерапевты **Носова** Елена Николаевнага, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең «Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү институты» федераль бюджет фәнни учреждениесе директорының фәнни эш буенча урынбасары, махсуслаштырылган консультация-диагностика поликлиникасы табибы – аллерголог-иммунологы **Решетникова** Ирина Дмитриевнага, «Тернәкләндерү» күппрофильле медицина ярдәме үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры – баш табибы **Хәсәнов** Гали Әхтәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Татарстан Республикасында (Татарстанда) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең санитария-химик тикшеренүләр һәм токсикологик-гигиена тикшеренүләре бүлегенең токсикологик-гигиена тикшеренүләре лабораториясе медицина оешмасы химигы-эксперты **Андреева** Светлана Ильиничнага, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының махсус программалар һәм проектлар эшләү һәм гамәлгә ашыру бүлеге әйдәүче консультанты **Газизова** Ләйсән Рөстәм кызына, «Татарстан Республикасында (Татарстанда) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе Әлмәт филиалының Лениногорск районындагы бүлекчәсе санитария-химик лабораториясе фельдшер-лаборанты **Идрисова** Миңнегөл Мөгыйн кызына, «Авиамедсервис» ябык акционерлык җәмгыятенең функциональ диагностика кабинеты шәфкать туташы **Мәүлетова** Антонина Александровнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең консультация поликлиникасы шәфкать туташы **Мохтарова** Фәнизә Бәһрам кызына, «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия бүлекчәсе операция шәфкать туташы **Хисамова** Лилия Фәһим кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Консалтинг Үзәге» акционерлык җәмгыяте генераль директорының производство экспертизасы буенча урынбасары **Хәмитов** Равил Әнвәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры урынбасары, эчке хезмәт генерал-майоры **Завгороднев** Алексей Анатольевичка **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЯҢА ШТАММ КУРКЫНЫЧМЫ?

Сәламәтлегебез өчен шактый катлаулы чорга аяк басабыз. Көз көне баш калкыта торган вируслы авырулар, грипп рәтенә соңгы ике елда «коронавирус» дигән зәхмәт тә өстәлде. Белгечләрнең, көзгә таба ковид белән авыручылар саны янә артачак, дигән фаразы чынга аша башлады инде. Соңгы бер тәүлек эчендә генә дә Татарстанда коронавирус йоктыруның 138 яңа очрагы ачыкланган. Белгечләр вирусның «кентавр» дигән яңа төре аеруча мәкерле булуы турында кисәтә. Бу, дөрестән дә, шулаймы? Коронавирусның яңа дулкыныннан нәрсә көтәргә?

Әлмәт үзәк район хастаханәсенең табиб-пульмонологы, гастроэнтеролог Рөстәм НАСРЕТДИНОВ әлеге сорауларга ачыклык кертте.

Соңгы арада коронавирус белән авыручылар саны арта бара. Әмма соңгы ике елдагы вазгыять белән чагыштырганда, хәзер ул җиңелрәк формада уза. Безгә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән балалар санының артуы күзәтелә. Әти-әниләр бик игътибарлы. Авыруның беренче билгеләре күзәтелүгә үк, «ашыгыч ярдәм» чакыра алар.

Хәзер коронавирус башка төр вируслы инфекцияләрдән аерылмый. Бүген ул еш кына гадәти салкын тию кебек кенә уза. Коронавирусны берничди билгеләрсез генә уздыручылар да шактый. Элегрәк аның төп билгесе саналган ис-тәм сизми башлаулар да хәзер күзәтелми диярлек. Шуңа күрә үзендә вируслы инфекция билгеләре сизгән кеше чынлыкта коронавирус белән авырырга мөмкин. Дару эчкәч тә төшми торган югары температура, баш авырту, көчле ютәл, аппетит югалу, хәлсезлек кебек билгеләр күзәтелсә, коронавирус түгелме икән дип шикләнергә җирлек бар.

Коронавирустан соң авырып терелгән кешедә еш кына йөрәк-кан тамырлары, сулыш алу, неврологиягә бәйле өзлегүләр күзәтелә. Әмма хәзер алар җиңелчәрәк уза. Дөрес, коронавирусның хәзерге яңа төре җитди өзлегүләргә дә китерергә мөмкин. Авырып терелгән кешедә хәтта менингит ук була ала. Әмма тулаем алганда, ковидның хәзерге төрен бик куркыныч дип санамыйм. Ник дигәндә, беренчедән, күбебез бу чир белән бер генә түгел, берничә кат авырып тереләде инде. Коронавируска каршы вакцина ясатучылар да шактый. Иммунитет бар. Шуңа күрә хәзер чирне һәм ковидтан соңгы чорны күпкә җиңелрәк уздырабыз да инде.

Коронавирус белән авыручылар саны ел саен артачак. Моңа ияләшергә туры килер. Бу шартларда фәкать иммунитетны ныгыту ягын гына кайгыртырга кирәк. Алар арасында иң нәтиҗәле ысул – ковидка каршы вакцина һәм ревакцинация ясату.

* Йөрәк-кан тамырлары, үпкә, калкансыман биз хроник авырулары булган, яман шеш диагнозы куелган, яше 65тән узган кешеләргә үз сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк.

Коронавирусның яңа төрен нинди билгеләр буенча чамаларга мөмкин? Андый чакта, беренчедән, кешенең берөзлексез тыны кысыла. Температура дару эчкәч тә төшми. Аппетит югала, кайчак кеше хәтта су да эчә алмый. Тәнне көзән җыерырга да мөмкин. Бу билгеләрнең берсе генә күзәтелсә дә, кичекмәстән «ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәк.

* Әйткәнемчә, соңгы арада балалар арасында да коронавирус белән авыручылар саны артты. Әмма хәзер алар да аны гадәти ОРВИ кебек уздыра. Әгәр баланың аппетиты югалса, тәнен көзән җыерса, температурасы төшмәсә, табибка күренергә кирәк.

Коронавирусны кисәтү өчен, иң беренче чиратта ковидка каршы вакцина яки ревакцинация ясатырга кирәк. Авырган кешеләрдән дә ерак торырга киңәш итәлә. Әгәр кеше бик нык ютәлли, борынына томау төшкән, температурасы югары, күзләре кызарган икән, бу кеше белән күрешми, аралашмый торуың хәерле. Кеше күп йөри торган җәмәгать урыннарында азрак булу, кеше арасында йөргәндә битлек кию мәслихәт. Битлекне еш алыштыру зарур. Көзге чорда һава торышына карап киенү, үткән җил искән җирләрдән ерак тору, туңудан саклану да хәерле.

Пешергәч файдалырак

Яңа өзелгән яшелчә, җиләк-җимеш иң файдалы ризык санала. Галимнәр исә башка фикердә.

– Помидор безнең организмга чи вакытына караганда, пешкән килеш күпкә яхшырак тәэсир итә. Дөрес, чи помидорда С витамины күп, аның каравы яман шеш авыруын кисәтә торган ликопин ферментын организм үзләштерә алмый. Бу фермент помидор күзәнәкләренең эчендә урнашкан. Шуңа күрә чи килеш ашаганда ашказаны аны эшкәртә алмый. Ә менә помидорны пешерсәң, күзәнәкнең тышы җимерелә, витаминнар исә бары тик 15 процентка гына кими.

– Бәрәңгене, киресенчә, мөмкин кадәр азрак пешерергә кирәк. Пешкән бәрәңгедә С витамины бөтенләй калмый.

– Кәбестәне дә артык пешермәү хәерле. Андагы файдалы матдәләрне үзләштерү өчен, аны аз гына кайнар суга салып тору да җитә. Кәбестә артык йомшарса, аның витаминнары юкка чыккан дигән сүз.

– Кишерне пешереп алсаң, яхшырак. Пешергәндә кишердәге каротин 4–5 тапкыр арта.

– Суган чи, пешергән, хәтта кыздырылган килеш тә бер үк дәрәҗәдә файдалы.

– Алмада С витамины күп түгел. Әмма аның составында йөрәк авыруын булдырмый торган антиоксидантлар күп. Бераз духовкада тыгып алсаң, алмада С витамины арта. Ә менә йомшарганчы пешерсәң, ул – ашказаны ялкынсынуыннан менә дигән дәва.

ТАШКАБАК

Август аеның иң мул нигъмәте – ташкабакның сәламәтлек өчен файдасы әйтеп бетергесез. Ул – файдалы диетик яшелчә, анда С витамины бар. Тән тиресенә, кан тамырларына уңай йогынты ясый. Шуңа күрә ташкабак запасы булганда ешрак кулланып калырга кирәк.

Калориясе иң аз булган яшелчә дә ул (100 граммында – 27 ккал). Клетчаткага бик бай булуы нәтиҗәсендә туклыклы да. Ташкабак организмда җиңел үзләштерелә, шунлыктан ашказаны, эчәкләр, бавыр ялкынсынганда (гепатит, холецистит, үт куыгында таш барлыкка килү) билгеләнә торган барлык диеталар составына керә. Сидек кудыру үзенчәлегенә ия булганлыктан, еш кына шешенүгә китергән йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан интегүчеләр өчен алыштыргысыз яшелчә.

Сорау – җавап

Казналыклар ник каный?

? Теш чистартканда, казналыклар канап интектерә. Ул ни сәбәпле каный икән?

Алсу САФИНА. Казан

Сорауга теш табибы Әлфия Зарипова җавап бирә:

– Күпләр теш щеткасын дөрес сайламый. Ул каты булса, теш казналыкларын бик тиз сафтан чыгарачак. Организмга К, С витамины җитмәгәндә дә теш казналыклары канарга мөмкин. Шуңа күрә күбрәк цитрус җимешләр, баллы борыч, кәбестә ашарга тырышыгыз. Казналыклар гингивит, пародонтит кебек авырулар вакытында да канарга мөмкин.

Белмәсәң бел!

Картаюдан саклый

Яшел борчак составында картаюдан саклый торган азык җепселләре, фолий кислотасы белән флавоноидлар күп, ди белгечләр. Яңа өзелгән борчакта ялкынсынуны киметә торган антиоксидантлар да бар. Алар яман шештән дә саклый.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара
ЗИННӘТУЛЛИНА

ҖИДЕ КАТ БЕЛЕШЕП, БЕРНЕ САТЫП АЛ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңа уку елы башланырга санаулы көннәр калып бара. Әмма мәктәпкә тулысынча әзер булганнар сирәктер. Чөнки алдан алып куелган уку формасы һәм аяк киемнәре кечерәергә мөмкин. Соңга калдым бугай дип борчылмагыз, әле соң түгел. Ә без исә, мәктәпкә җыенганда, акчаны янга калдыру ысулларын исегезгә төшерергә булдык.

Якында гына димә

Якындагы кибеттә барысы да бар, дип аннан алырга ашыкмагыз. Чөнки 1 сентябрьгә кадәр зур булмаган кибетләрдә бәяләр шактый тешли торган була. Зуррак сәүдә үзәкләрендә исә, киресенчә, уку елы башланыр алдыннан мәктәп формасына, канцелярия товарларына, аяк киемнәренә ташламалар ясыйлар. Мәктәп кирәк-яраклары алырга чыгар алдыннан, иренмичә сайтларны карап чыгыгыз. Бәяләрне карап, язып, чагыштырганнан соң, шактый акчагызны янга калдырырга мөмкин булачак. Ташламалы әйберләрне махсус кушымталарда (SkidkaOnline, «Акции всех магазинов России») да табарга була.

Берләшү отышлы

Әти-әниләр чатлары уку елы алдыннан тагын да җанланып китә. Анда берләшеп, эш дәфтәрләре, контурлы карталар, китап, уку әсбаплары, спорт киемнәре алган очракта шактый акчаны янга калдырып була. Күпләп алу һәрчак отышлы, ә берәр әти-әнинең ташламалы картасы да булса, чыгымнарны 15 процентка кадәр киметергә мөмкин.

Кешбэк куллан

Нәрсә дә булса сатып алганнан соң чыгымның бер өлешен кире кайтару хәзер бөтен банкларда да бар диярлек. Банкларның партнерлары булган кибетләрдә карта белән түләгән очракта акчаның бер өлеше шундук кире кайта. Кешбэкны ничек кулланырга икәнне белмәгән очракта, банк хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итәргә була. Шул рәвешле товар бәясенең 30 процентка кадәрен кире кайтару мөмкин. Шулай кайбер кибетләрнең дисконт карталарына җыелган баллар белән дә чыгымны шактый киметергә була.

Сайттан яңаны эзлә

1 сентябрь алдыннан мәктәп кирәк-яракларын онлайн «барахолкалар»дан табарга мөмкин. Анда кемдер алдан алып куеп кечерәйгән, киелми калган яңа форма, спорт киемнәре, букчаларны ташламалы бәядән алырга була. Башкалар алганчы тизрәк онлайн түләп калыйм дип ашыкмагыз һәм карта мәгълүматларын чит-ятларга бирә күрмәгез.

Артыгын сатарга куй

Интернетта хәзер арзанга сатып алу гына түгел, шулай ук үзеңдәге киелми калган яки киелсә дә төсен җуймаган әйберләрне, мәктәп әсбапларын сату өчен дә кулай вакыт. Кечерәйгән, алып та ошамаган, кирәкмәгән әйберләрне һич кыенсынмый сатарга куя аласыз. Тамчылардан күл җыела, сатудан кергән акчага өстәп яки шул бәягә башка кирәк-яракларны алырга мөмкин бит.

Кичектереп тор

Хәзер алып куям да, эш бетә дип ашыкмасагыз да була. Әлбәттә, беренче сентябрьгә баланы яңа кием, букчалар белән җибәрәсе килә. Ә 2–3 атнадан соң шул ук әйберләрне 50 процентка кадәр ташламалар белән алырга да мөмкин. Әгәр балагызның уку формасы хәзергә таман, ә уку елы уртасына кадәр кечерәясен чамалыйсыз икән, зурраклы ташлама белән алып кую да комачау итмәс.

Исеңдә тот

Дөрес сакла, атмасын!

Кышка әзерләнгән салат, тозланган яшелчә, кайнатмалар кайчак саклауга куйганчы ук төсен үзгәртеп, капкачы кабарып, кәефне кыра. Моны булдырмас өчен, түбәндәгеләрне истә тотыгыз.

✓Бераз гына булса да изелгән, тәме, төсе үзгәргән яшелчә, җиләк-җимешләрне кышка әзерләү өчен кулланмагыз.

✓Тозның вагын һәм йодлысын кулланмаска тырышыгыз. Кәгазь капчыклардагы таш тоз яки тозлау өчен махсус тоз куллансагыз, кышка әзерләгән ризыкларыгыз озак сакланыр.

✓Фильтрдан чыгарылган су яки чишмә суы куллану яхшы.

✓Яшелчәләрне яхшылап юарга, банкаларны стерильләштерергә онытмагыз.

✓Тозлау, кайнатма саклау, салат ясау өчен кечкенә банкалар куллану яхшы. Чөнки алар тиешенчә эшкәртү, саклау һәм йөртү өчен бик уңайлы. Вак банкалар ачканнан соң ук ашалып та бетә, исраф булмый.

Белеп тор!

Кайсы нинди?

Савыт-саба юа торган губкаларның нигә төрле төстә икәнлеген белә идегезме? Аның сере гади: ул губка өстенә ябыштырылган катламның катылыгын билгели икән. Яшел төс – иң катысы, кызыл белән зәңгәр – уртача, ә сары йомшак дигәнне аңлата.

Матур бул!

ЯШЕЛ ЧӘЙ ЧИСТАРТА

Биттәге таплардан һәм туттан котылырга теләсәгез, әлеге битлекне ясап карагыз. Ике аш кашыгы яшел чәйне порошокка әйләнгәнче изәргә. Аңа ике чәй кашыгы дөге оны кушарга. Куе масса барлыкка килерлек итеп, су белән болгатырга. Пигмент таплары булган урыннарга сөртеп чыгарга. Битлекне 15 минут тоткач юып төшерергә.

Тәмле булсын!

vk.com

ӨЙ КЕТЧУБЫ

Кирәк: помидор – 3 кг, алма – 0,5 кг, суган – 0,25 кг, тоз – 1,5 аш кашыгы, шикәр комы – 1,5 стакан, алма серкәсе – 50 г, тәменчә кара һәм кызыл борыч.

Әзерләү: барысын да турап, суган йомшарганчы пешерергә. Аннары блендер белән изеп, теләгән куелыкта итү өчен 50 минут чамасы әкрен утта тотарга. Әзер булыр алдыннан тоз, шикәр, борычны өстәп, кайнатып чыгарырга һәм кайнар килеш стерильләштерелгән банкаларга тутырырга. Кетчуп баллы булсын дисәгез, алмасын арттырырга, үзгә тәм булсын өчен сарымсак өстәргә дә мөмкин.

Бакчачыга

«Көйле» 5 чәчәк

Бакчагызда күзне иркәләүче, көйсез булмаган чәчәкләр үстерим, дисәгез, түбәндәге исемлек – сезнең өчен. Алар тәрбиягә нәзберек түгел, әмма бик матурлар!

3 **Нәркис**

1 **Лофант**

4 **Мускари** (гиацинт)

2 **Аквилегия**

5 **Ирис**

УКУ ДА, УКЫТУ ДА – САВАП

1 сентябрь – Белем көненә санаулы көннәр калып бара. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Галимнең гыйбадәт кылучы (белемсез) кешедән өстенлеге айның бөтен йолдызлардан да өстен булганы кебек. Галимнәр алар – пәйгамбәрләрнең варислары. Пәйгамбәрләр динарны да, дирһәмне дә мирас итеп калдырмадылар, алар бары тик гыйлемне генә калдырдылар. Кем дә кем аны алса, үзенә җитәрлек дәрәҗәдә алган булыр», – диелә.

Мөхәммәд хәзрәт МИФТАХОВ белән уку, белем алуның ислам динендә тоткан урыны, нечкәлекләре турында сөйләшәбез.

:: Мөхәммәд хәзрәт, ислам динендә белем ул – ...

– ... фарыз гамәл. Аллаһы Тәгалә, иң беренчеләрдән булып, белемгә бәйле аятьне индергән. Коръәннең иң беренче иңгән шушы аятендә («Галәк» сүрәсе) Ул: «Сине барлыкка китергән Раббың исеме белән укы!» – дип, белем алырга чакыра. Бу хәдистән күренгәнчә, динебез белем белән башлана. Белмисең икән – эшләмә. Кем дә кем белмичә берәр нәрсә эшли икән, файдага караганда, зыяны күбрәк китерә. Ислам динендә белем алу хатын-кызга да, ир-атка да бер үк дәрәҗәдә фарыз булып тора. Монда, дөньяви белемнән бигрәк, дини белем турында сүз бара.

:: Өйрәтеп калдырган файдалы гыйлем өчен савап кеше үлгәч тә килеп торачак, диләр. Бу, дөрестән дә, шулаймы? Димәк, белем алучы гына түгел, аңа белем биргән укытучы, мөгаллим дә савап эшли булып чыга?

– Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кеше үлгәннән соң бөтен гамәлләр киселә, әмма өч төрле гамәл үлгәннән соң да аңа савап китереп тора», – ди. Шуларның берсе – «җәрия сәдака»сы (ягъни җәмгыятькә файдалы эш эшләп калдыру), икенчесе – файдалы белем, өченчесе – баланың догалары. Әгәр кеше үз артыннан берәр кешене өйрәткән, укучы булганы шуннан файдалана икән – белем биргән кешегә үлгәннән соң да әҗер-савабы булачак. Шул рәвешле белем алганда, укучы да, укытучы да савап җыя. Пәйгамбәребез дә: «Иң яхшыларыгыз – кем Коръән өйрәтә, йә өйрәнә», – ди. Тагын бер хәдисендә ул, белем юлына чыккан кеше өчен җирдә дә, күктә дә барлык нәрсә, хәтта судагы балык та дога кыла, дигән мәгънә җиткерә.

:: Бүген күпләр түләүле бүлекләрдә белем ала. Акча түләп, белем алу дөресме?

– Бу очракта иң элек белемнең кайсы төре турында сүз баруына ачыклык кертергә кирәк. Дини белем сатылмаса хәерлерәк. Ләкин әгәр кешенең башка чарасы юк, шушы белемнән башка ул ризыксыз кала икән, акча түләп укуның зыяны юк. Әмма бу очракта бер искәрмә бар. Коръән укырга өйрәткән өчен акча алырга ярамый. Әмма кеше аңа сәдака рәвешендә яки ярдәм йөзеннән, үзе теләп, акча калдыра икән, моның зыяны юк. Дөньяви белемгә килгәндә, монда акча түләп укуның бер гаебе дә юк.

:: Кредит алып, баланы югары уку йортына укырга керту дөресме?

– Юк, бу – дин тарафыннан тыелган гамәл. Ислам динендә кредит алу гөнаһ санала. Аллаһка шөкер, бүген түләүсез дә белем алып була. Сайлау мөмкинлеге бар. Шуңа күрә бу очракта агыймны юрганыңа карап сузу дөресрәк.

:: Кайбер ата-ана баланың букчасына дога салып җибәрә. Болай эшләргә ярыймы?

– Бала бу доганы алып укымаса, аны букчага салып җибәрүдән генә файда юк. Бу китап баланы саклый, яклый дип күңел юатырга кирәкми. Кемдер моны күптәннән килгән гадәт, дияр. Әмма бу – борынгыдан килгән гадәт түгел, коммунизм чорыннан калган күренеш. Ул чорда дини белемгә бик зур кытлык иде.

:: Еш кына бала берничә ел бер белгечлекне үзләштерергә укый да, укып бетергәч, үз һөнәре буенча эшләми. Бу белемне исраф итү саналмыймы? Андый чакта ата-ананың баланы укытуга еллар буе түккән көче, тырышлыгы да әрәм булган кебек тоела бит. Моны ата-ананың ризалыгын алмау дип тә бәяләп буламы?

– Монда һәр очракка шәхси якын килергә кирәк. Төгәл генә җавап юк. Бер яктан, әлбәттә, кеше укып чыгып, башка юнәлештә эшләсә дә, ул алган белемнең барыбер файдасы булачак. Икенче яктан, баланың ни өчен бу адымга барганын да ачыкларга кирәк. Сорауның икенче өлешенә килгәндә, ата-ана теләгән белгечлек буенча эшләмәү берничек тә аларның ризалыгын алмауга тиң була алмый. Бу – бөтенләй башка очрак.

:: Укырга барганда, өйдән чыгып киткәндә, нинди дога укырга кирәк?

– Теләсә кайсы эшне башлаганда, мөселман: «Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим бисмилләһир-рахмәнир-рахим», – ди. Укырга барганда да бала шушы доганы укып чыкса, хәерле. «Бисмиллә тәвәккәлтү галәллаһ» («Аллаһы исеме белән Аллаһка тәвәккәлләдем») дип дога кылуның да файдасы зур.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сентябрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беләнә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Пәнҗ	02:21	04:47	16:23	18:38	20:32
2	Җом	02:24	04:49	16:21	18:35	20:29
3	Шим	02:28	04:51	16:19	18:33	20:26
4	Якш	02:31	04:53	16:17	18:30	20:22
5	Дүш	02:34	04:55	16:15	18:27	20:19
6	Сиш	02:37	04:57	16:13	18:25	20:16
7	Чәрш	02:40	04:59	16:11	18:22	20:13
8	Пәнҗ	02:43	05:01	16:09	18:20	20:09
9	Җом	02:46	05:03	16:07	18:17	20:06
10	Шим	02:49	05:04	16:05	18:14	20:03
11	Якш	02:51	05:06	16:03	18:12	20:00
12	Дүш	02:54	05:08	16:01	18:09	19:57
13	Сиш	02:57	05:10	15:59	18:06	19:53
14	Чәрш	02:59	05:12	15:57	18:04	19:50
15	Пәнҗ	03:02	05:14	15:54	18:01	19:47
16	Җом	03:05	05:16	15:52	17:59	19:44
17	Шим	03:07	05:18	15:50	17:56	19:41
18	Якш	03:10	05:20	15:48	17:53	19:38
19	Дүш	03:12	05:22	15:46	17:51	19:35
20	Сиш	03:15	05:24	15:43	17:48	19:32
21	Чәрш	03:17	05:26	15:41	17:45	19:29
22	Пәнҗ	03:20	05:28	15:39	17:43	19:26
23	Җом	03:22	05:30	15:37	17:40	19:23
24	Шим	03:25	05:32	15:34	17:37	19:20
25	Якш	03:27	05:33	15:32	17:35	19:17
26	Дүш	03:29	05:35	15:30	17:32	19:15
27	Сиш	03:32	05:37	15:28	17:30	19:12
28	Чәрш	03:34	05:39	15:25	17:27	19:09
29	Пәнҗ	03:36	05:41	15:23	17:24	19:06
30	Җом	03:38	05:43	15:21	17:22	19:03

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Ике авыру

(ГЫЙБРӘТЛЕ КЫЙССА)

Хастаханәдә ике урынлы бүлмәдә ике авыру яткан. Аларның икесендә дә нәкъ бертөрле урын-җир, бертөрле шартлар... Әмма авыруларның берсе, бердәнбер тәрәзәдән карап яткан, икенчесе янында шәфкать туташларын чакыра торган төймә урнашкан.

Вакыт үткән, ел фасыллары алышынган... Тәрәзә янында ятканы дустына урамда күргән һәр нәрсәсен тәфсилләп сөйләп биргән: яңгыр сибәли, кояш яктырта, агачларга бәс кунган, салмак кына сары яфраклар коела, кешеләр һәм машиналар йөри. Анда дөнья бар.

Ләкин көннәрдән беркөнне тәрәзә янында ятканының хәле начарлана, ә тегесе нишләптер шәфкать туташын чакырмый. Нәтиҗәдә авыру үлеп китә. Икенче көнне палатага бүтән авыруны китерәләр һәм тегесе, мөмкинлектән файдаланып, тәрәзә янына күчеп ята. Ә анда... Ул тәрәзәнең бер стенага чыгуын, анда сорылыктан башка берни дә булмавын күреп ала. Күпмедер вакыт дәшми торгач, күршесенә болай ди:

– Беләсеңме, төнлә хәлем начарланса... шәфкать туташын ярдәмгә чакырма.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ИҢ ЧИБӘР ТАТАР ЕГЕТЕ – 😍 ?

Nubia онлайн журналы дөньядагы иң чибәр ир-атны ачыклаган. Сораштыруда катнашучылар арасында иң күп тавышны Кытай җырчысы, актер Сяо Чжань җыйган. Без исә танылган татар егетләре арасында иң чибәрен ачыкларга булдык һәм «ВК»дагы төркемебездә сораштыру уздырдык. Нәтиҗәләре – түбәндә.

Илназ Гарипов

Илшат Сафин

Марат Яруллин

Рамил Шәрәфиев

Ренат Галиәскәр

Ришат Төхвәтуллин

Эльмир Низамов

Булат Мусин

Ришат Әхмәдуллин

Чибәр егет	Тавыш	%
1. Илназ Гарипов (җырчы)	88	10,27
2. Илшат Сафин (җырчы)	144	16,8
3. Марат Яруллин (җырчы)	67	7,82
4. Рамил Шәрәфиев (алып баручы)	50	5,83
5. Ренат Галиәскәр (шагыйрь)	38	4,43
6. Ришат Төхвәтуллин (җырчы)	177	20,65
7. Эльмир Низамов (композитор)	48	5,6
8. БУЛАТ МУСИН (көрәшче)	178	20,77
9. Ришат Әхмәдуллин (актер)	67	7,82

*Узган атнадагы санда чыккан «Ә син таныйсыңмы?» уенында дөрес җавапны беренчеләрдән булып Казаннан **Алсу Шакирова** җибәрде. Афәрин! Рәсемнәр астына без Ләйсән Гыймаеваның «Яшим синең кочагыңда», Хәйдәр Бигичев репертуарыннан «Әйткән идең» һәм Салават Фәтхетдинов башкаруындагы «Юрамагыз сагышка» җырларын яшергән идек.*

Матурлык туйда гына кирәкме?

Матурлык турында сөйләшүебезне дәвам итеп, бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсе кунаклары – чибәр затларның фикерләрен белештек. «Матурлык туйда гына кирәк» дигән әйтем белән килешәме алар?

«ГАИЛӘСЕНЕҢ ТОТКАСЫ БУЛСЫН!»

Фәйрүзә МӘҖИТОВА, «ТНВ» телеканалы алып баручысы:
– Мин бу фикер белән килешәм. Ир-атка гаиләсен кайгыртып, тормыш алып бару өчен акыл, күңел һәм иман байлыгы, юмор, җитезлек, кайгыртучанлык кебек сыйфатлар тышкы матурлыкка, чибәрлеккә караганда күбрәк кирәк. Күңеле бай булган, үз гаиләсенең токасы булган ир-ат ул – иң матур кеше!



«ТЫШКЫ КЫЯФӘТКӘ КАРАП ГАШЫЙК БУЛМАДЫМ»

Резедә СӘЛАХОВА, Тинчурин театры артисты:
– Иртәнге якта ук кибетләрдә кайнар көлчә булсын өчен, мин төнге икедә торып эшкә керәм. Иң элек камыр басам. Әлегә бу эшне кул белән башкарам. Киләчәктә миксер алып куясым, аннары тагын бер тандыр урнаштырасым килә. Әлегә артык акча керми, киресенчә чыга гына. Бар продукция кыйммәт. Кешегә ошасын, тәмле булсын өчен тырышам. Элегрәк көнгә 30 көлчә сату кыен булса, хәзер белеп бетерделәр. Көнгә 400ләп көлчә дә җитми кайчак. 13 кибет белән килешү төзедек. Алар сатып бирә, – ди Гөлсорахан.

Планнары зурдан аларның. Кафе ачарга, район халкын милли ризыклар белән сыйларга исәпләре. Хәтта исемен дә уйлап куйганнар. Мәскәүгә киткән уллары да, Татарстанга кайтып, әти-әниләренә булышмакчы.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

«БАРАБАН»

80 ел элек, 1942 елның 9 августында ачтан шешенгән, үлем белән күзгә-күз карашып яшәгән Ленинград халкы филармониянең концерт залына Дмитрий Шостаковичның Җиденче («Ленинград») симфониясен тыңларга җыела. Быел юбилей уңаеннан бу музыка кабат яңгырады. Аңлашыла ки, матбугат чаралары мондый вакыйганы читтә калдырмады.

Р.Зарипов архивыннан

Җәүдәт Айдаров (беренче рәттә уң яктан өченче) Ленинградта фронтташ дуслары белән.

«Ул үләргә тиеш түгел!»

Бәлки, игътибар иткәнсездер, кыска гына мәгълүматларда, хәтта Мәскәү каналларыннан күрсәткәндә дә, еш кына милләттәшебез Җәүдәт Айдаров исеме телгә алынды.

Симфониядә кеше саны аз түгел. Шундук «Җәүдәт Айдаров башкалардан нәрсәсе белән аерылып торган?» дигән сорау туа. 80 елдан соң да телгә алып сөйләрлек нинди вакыйга булган? Дирижер Карл Элиасберг оркестрга музыкантларны бик авырлык белән җыя. Кемдер фронтка юл ала, икенчеләре ачлыктан яки авырудан үлеп китә. Күбесе аякларында көчкә басып торалар. Репетицияләр берничә ай дәвам итә. Беренчесенә 28 кеше килә, ә партитура буенча 80нән артык музыкант кирәк. Аларга хәрби округның күрсәтмә оркестрыннан Җәүдәт Айдаров та килеп кушыла. Көнгә өч тапкыр өчәр сәгатьлек репетиция. Кирәк икән, һәр фразаны йөзәр тапкыр кабатлыйлар. Ачлыктан егылучыларның саны артканнан-арта бара. Бердәнбер көнне барабанчы Җәүдәт Айдаров та юкка чыга. Дирижерга аның урамда егылуын һәм гәүдәсен моргка төяп китүләрен җиткерәләр. «Юк, ул үләргә тиеш түгел!» – дип, дирижер йөгереп чыгып китә һәм барабанчысын хастаханәдәге мәетләр яткан бүлмәдән эзләп таба. Кулларын тотып караса, егетнең бармаклары селкенә. Бу – Җәүдәтнең икенче тапкыр дөньяга килүе була. Шул җәһәттән шагыйрә Ольга Берггольцның «Ленинград хәбәр итә» дигән шигырендә мондый юллар бар: «Үлә беренче скрипка, эшкә барган чакта үлә барабан да...» Ләкин «барабан» исән кала. Ул бәрмә инструментларда фашистларның Ленинградны басып алырга җыенган мәлдәге ямьсез адымнарын тасвирлый, бирешмәскә, көчле булырга өнди.

Симфонияне башкарган көндә оркестрда бары... 15 кенә музыкант исән кала. Алар арасында Җәүдәт бердәнбер татар егете була.

Җиденче симфония

Композитор бу әсәрне Бөек Ватан сугышының беренче атналарында иҗат итә башлый. Шул ук вакытта башкалар белән бергә танкка каршы ныгытмалар төзи, төннәрен очырмаларга менеп, кизү тора, өй түбәләрендә янгын сүндерә. 1941 елның сентябрь ахырына симфониянең өч өлеше язылып бетә. Октябрь аенда исә композиторны ике баласы белән эвакуациялиләр. Ул эшен дәвам итә. 1942 елның 5 мартында Куйбышев шәһәренең Опера һәм балет театрында симфониянең премьерасы була. Камалган Ленинградта симфонияне башкару инициаторы – Ленинград радиокомитетының Зур симфоник оркестры дирижеры Карл Элиасберг. 1942 елның июлендә партитура самолет белән Ленинградка китерелә һәм репетицияләр башлана. 9 августта (бу көнне немец командованиесе Ленинградка зур һөҗүм планлаштыра) филармониядә Җиденче симфония яңгырый. Ул 80 минут дәвам итә. Тәрәзәләр капланган. Бәллүр лампалар тулы куәтенә яна. Алкышлардан алар зеңгелдәп торалар. Зал тулы була. Музыкантларны совет артиллериясе саклый. Өмет рухы белән сугарылган бу музыка яралыларның тәненә шифа була. Ул көнне газеталар: «Җиденче симфония – киләчәк җиңүебезгә багышланган поэма булды», – дип язалар. Иң гаҗәпләндергәне шул: симфония башкарылганда, дошман артиллериясенең бер генә аткан тавышы да ишетелми. Музыканы тавыш көчәйткечләр аша шәһәр халкы гына түгел, Ленинградны камап алган немецлар да ишетә.

Түнтәр

Җәүдәт Айдаровның эзләре Балтач районындагы Түнтәр авылына барып тоташа. Ул үзе 1918 елның 31 декабрендә Пермь шәһәрендәге Җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы Карәмәтулла хәзрәт гаиләсендә туа. Әнисе Латыйфа исә Түнтәр авылында яшәгән, тирә-якта дан тоткан Ишмөхәммәт ишанның кече кызы була. Бу хакта без әлеге авылның үткәннәрен барлап китаплар язучы, туган як тарихы музеен булдыручы Рәфхәт абый Зарипов белән сөйләштек.

– Бик талантлы егет була ул. Бәрмә инструментларда уйнагач, аңа «Барабан» дигән кушамат та тагыла. Бабасы, 80 яшьлек Ишмөхәммәт ишанны 1919 елда Малмыжда бернинди судсыз-нисез атып үтерәләр. Абруе зур булганга, большевиклар, Колчак гаскәрләре килеп җиткәч, кешеләрне үз артыннан иярттер, дип куркалар. Шулай да, халыкның да күтәрелүеннән куркыпмы, кайбер чигенешләр дә ясамакчы булалар. Ике малаеның берсе – педагог, икенчесе – кызылармияче. Аларга: «Әтиегезне порукага алсагыз, атып үтермибез», – диләр. Әмма Ишмөхәммәт ишан баш бирми. Пермьдә яшәүче Латыйфа кызының гаиләсе дә репрессиягә эләгә. Ике уллары – Җәүдәт белән Тәлгать Ташкенттагы балалар йортында тәрбияләнә. Ул вакытта Җәүдәткә 10 яшь була. Малайның талантын күреп, шундук балалар йорты каршындагы тынлы уен кораллары оркестрына чакыралар. Аннан соң ул бөтен гомерен музыкага багышлый. Ташкент опера һәм балет театрларында, Горький һәм Киев шәһәрләренең театрларындагы оркестрларда уйный. 1937 елдан Мәскәүдәге Киров театрында эшли. Берәттән музыка училищесы студенты да була.

Сугыштан соң

Сугыш тәмамлангач, Җәүдәт Айдаров Ленинград консерваториясенең дирижерлык-хор бүлеген тәмамлый. Бик күп шәһәрләрдә эшли. Гомеренең соңгы елларын Татарстан белән бәйли. 1956 елдан башлап 1965 елга кадәр Татарстан АССР җыр һәм бию ансамблен җитәкли. Ул эшләгән чорда ансамбльгә Габдулла Тукай исемендәге премия бирелә. Аннан соң Казан консерваториясендә укыта, консерватория каршындагы урта махсус музыка мәктәбенең директоры була. Казан музыка училищесында белем бирә. Күп төрле орден-медальләр белән бүләкләнә, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исемгә лаек була.

Аның тормыш иптәше Зәйнәп Хәйруллина да бик күренекле шәхес иде. Озак еллар татар радиосында эшләде. 1957 елда Мәскәүдә тарихка кереп калган татар декадасы булды. Ул шунда концертны алып барды.

Рәфхәт абыйдан: «Җәүдәт абый Түнтәргә кайтып йөрдеме? Очрашканыгыз булдымы?» – дип сорыйм.

– Кайта алмады шул, – диде ул. – Үзем Казанга барып күрештем. Тик вакыты юграк чакка туры килдем бугай. Озак сөйләшә алмадык. Балалары юк иде аларның. Хатынының сеңлесе Фәридәнең улын бергәләп үстерделәр. Шул уллары кайтып киткән иде. Әниләре Латыйфа исә Түнтәргә еш кайтып йөри. Ишмөхәммәт хәзрәт үзе безнең авылга Мамадыш районындагы Сон авылыннан мәдрәсәгә укырга килә. Уку йортын тәмамлагач, бөтенләйгә Түнтәрдә, хәлфәлек эшендә кала. Аның үз тарихы бар инде. Заманында Мөхәммәтгали ишан монда зур мәдрәсә ача. Бер генә кызы булганлыктан, бар булган байлыгын, шул исәптән мәдрәсәне дә Кукмара төбәгеннән килгән кияве Шәмсетдингә тапшыра. Бер 10 ел тирәсе хезмәт иткәннән соң, ул хаҗдан кайтканда авырып үлә. Аны Истанбулда җирлиләр. Малае 10 яшьлек булып кына кала. Бу яшьтә указы булмый бит инде, шуңа имам-хатыйп итеп Ишмөхәммәтне сайлап куялар. Ул 42 ел буена шушы вазыйфада кала. Шәмсетдин улы Мөхәммәтнәҗип тә үсеп җитә. Төрле илләрдә белем ала, җәдитчелекне яклый. Ишмөхәммәт ишан исә кадимче була. Шулай итеп, ике нәсел арасында каршылык килеп туа. Ишмөхәммәт ишанны сөргенгә җибәрү турындагы карар да шушы низагка бәйле түгелме икән дигән фаразлар бар. Ничек кенә булса да, ул халык күңелендә яши. Безнең өчен бу нәсел бик кадерле. Җәүдәт Айдаровның кабере дә – Түнтәр зиратында. Үзенең васыяте буенча җирләнде. Шәхси пианиносын, кайбер истәлекләрен авылдагы музейга бүләк итте. Барысын да кадерләп саклыйбыз. «Барабан» рухы Түнтәрдә яши.

Җиденче симфония турында

- Җиденче симфония – классик музыка тарихында иң сәясәтләштерелгән әсәр. Бу көнне фашистлар Ленинградны күлгә әйләндерергә җыеналар. Премьера яңгыраганнан соң җиңүченең кем булачагы ачыклана.
- Симфониянең беренче өлешендә яңгыраган музыка «Ленинград симфониясе» дип аталган балетка нигез итеп алына.
- 2015 елны симфония Донецк шәһәренең филармониясендә яңгырый. Ул махсус проект кысасында оештырыла.
- Шагыйрь Александр Межиров бу әсәргә багышлап шигырь яза.
- Сугыштан соң бер немец болай дип язып калдыра: «Нәкъ менә «Ленинград симфониясе» яңгыраган көнне без бу сугышта җиңеләчәгебезне белдек. Ул көнне ачлыкка да, үлемгә дә бирешмәгән совет халкының көчле булуын аңладык».

«ИКЕДӘН УНАЛТЫ БУЛДЫК»

Мамадыш районының Югары Тәкәнеш авылында гомер итүче Гөлия һәм Рәис Саматовлар гаиләсе Кремльдә кунак булып кайтты. Президент чакыра дигәч, төнлә йоклап та тормаганнар. Гөлия ханым әйтүенчә, иртәнге өчтә инде аякта булганнар.

– Гомеремдә дә Президент янына барырмын, аның белән бер табын янында сөйләшеп утырырмын, бергә чәйләр эчәрмен, димәгән идем. Районнан хәбәр килгәч, башта бик дулкынландым. Анналары инде, чакыргач, барырга кирәк, дип тынычландым, – дип сөйли Гөлия ханым. – Районның ЗАГС идарәсе җитәкчесе Ландыш Шәйхетдинова бик ярдәм итте. Әгәр ул тынычландырып тормаса, ни эшләп беткән булыр идек? Хәтта күлмәкне дә үзе сайлап бирде. 50 яшемә җиткәндә, беренче тапкыр матурлык салонына кереп, бизәнеп чыктым. Шаккатмыч бит бу. Үз гомеремдә матурланып йөргәнем булмады. Район башлыгы Анатолий Ивановка да рәхмәт. Казанга чыгып киткәндә, үзе озатып калды. Президент янында каушап калмасыннар дип, репетиция ясаткандыр.

Җитмәсә, урыннары да Рөстәм Миңнеханов һәм аның хатыны Гөлсинә ханым янәшәсендә туры килгән. Президент, аларның Мамадыштан икәнен белеп алгач, бөтенләй ачылып китә. Әтисенең Дусайдан икәнен әйтә, үзенең дә анда еш булганын сөйли. «Якташлар икән без», – диюе Саматовларга бөтенләй канат куя.

– Табын янында шушы зур дәрәҗә өчен Аллаһы Тәгаләгә чиксез рәхмәтемне әйтеп утырдым. Ә бит минем тормышым рәхмәт әйтмәслек түгел. Мин бар дөньяны яратып яшим. Диндә булуым миңа бик ярдәм итә. 33 яшемдә ныклап намазлар укый башлаган идем инде мин, – ди Гөлия ханым. – Сигез балам да – көтеп алынган сабыйлар. Әнием бер ялгызы гына үсә. Сәламәтлеге буенча бала табарга ярамаса да, ул дүрт бала алып кайта. Безгә гел бер киңәш бирде: «Бала алып кайтудан курыкмагыз», – дия торган иде. Бәбигә узуга, әнинең сүзләре исемә төште. Мин балаларны авырлык белән күтәрмәдем. Хәтта үстергәндә кешегә кыенлык тудырмаска тырыша идем.

Саматовларның олы уллары Рәмискә 28 яшь икән инде. Гаиләкорып, хатыны белән ике бала үстерәләр. Кызлары Гөлгенә дә, Гүзәл дә кияүдә. Рәмзилләре быел югары уку йортына кергән, Рамазан исемле уллары Мамадыштагы көллияттә белем ала. Исламия, Сөмбел, Мөхәммәтгазиз авыл мәктәбендә укыйлар. Ире гомере буе тракторда эшли. Аның өйгә кайтып кергәне дә юк икән. Алдынгылыкны бирмәс өчен, көн-төн эшли, ди хәләле.

Гөлия ханым, һәр бала үз ризыгы белән туа, дигән фикердә. Аларга дөрес юл күрсәтсәң, бар да үз җаена бара, ди ул.

– Район хакимияте ярдәменнән ташламый. Безгә Мамадыштан ике фатир бирделәр. Ике улым шунда яши. Үз өебез дә зур. Ялларга бергә җыелганда, 16га тулабыз. Сигез бала үстердем, киленнәркияүләр, оныклар белән ике тапкыр арттык. Әле тагын ишәяселәр алда, – ди.

Ул бер дә зарланмый. Сигез баланы аякка бастыру җиңел булмагандыр, дип тә карыйм. Ә ул исә, кулың эш белсә, бала үсә ул, дип кенә сүзне икенчегә бора.

– Бер пешергәндә мичкә зур табада сигез ипи тыга идем. Көн саен шулай итеп пешердем. Ашны да зур кәстрүлдә әзерләдем. Олыраклары үсә башлагач, эне-сеңелләрен караштылар. Мин үзем дә иркә хатын булмадым. Бала табу йортына киткәнче, өч сыерны савар идем. Бервакыт тулгагым башланды. Туктагансыер савам. Үзем эчемнән генә уйлыйм: тибеп кенә җибәрмәсен иде. Күршеләргә савасы булмасын дип тырыштым. Сөтләрне урнаштырып бетергәндә, ул балам туа башлаган иде инде. Мине Мамадышка түгел, якынрак дип, Кукмарага алып чаптылар, – ди ул.

Саматовларның шәхси архивыннан

Ни генә сөйләшсәк тә, сүз Казандагы очрашуга килеп тоташа. Аларга Президент мактаулы исем белән акчалата бүләк кенә түгел, зур телевизор да биреп җибәргән.

– Бүләк өчен бала тапмадым бит мин. Гаиләбезне зурлаган өчен зур рәхмәт. Әмма иң зур теләгем – балаларымның игелекле, сау-сәламәт, гомерле булуы. Авырмасыннар гына, – ди Гөлия ханым. – Президентның ягымлы елмаюы, гадилеге, хатынының безгә булган хөрмәте күңелебездә озак сакланыр әле. Балаларга, оныкларга сөйләрлек булды бу!

Сан

✓ Соңгы елларда республикада **1000**гә якын гаилә «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медаленә ия булды. Алар барысы да **25** һәм аннан да күбрәк ел бергә яшәгәннәр.
✓ **2022** елның беренче яртысында **700** пар – **50** ел, **156** пар **60** ел бергә гомер итүләрен билгеләп үтте.

БЕРЕБЕЗ ЮГАННЫ ИКЕНЧЕБЕЗ ӘЛЕП БАРДЫ

Буа районының Кырык-Садак авылында гомер итүче Хәйруллиннарга да Президент һәм аның хатыны белән очрашу насыйп булган.

Хәйруллиннарның шәхси архивыннан

Хис-кичерешләре әйтеп аңлатырлык түгел. Әмма алар бер дә каушамаган. Президент янына шатланып барганнар. Мөслимә апа иң матур күлмәген кигән, Искәндәр абыйга да шкафтан пинжәкчалбарын чыгарырга туры килгән. Матур итеп пардан киенгән алар. Зәңгәр төсне сайлаганнар.

– Телевизордан Рөстәм Миңнехановның гадилеген күреп шакката идек. Үзен күргәч, аңладык инде. Йөзеннән нур бөркелә бит аның. Шундый кеше ничек гади булмасын инде! Кешене үзенә карата белә ул. Янібызга килеп, хәлебезне сорап, кочаклап фотога да төште әле. Менә җитәкче шундый булырга тиеш. Мин Президент дип борынын чөеп йөрми, – ди Мөслимә апа. – Их, мондый очрашулар без яшь вакытта булмады, дим дә, аннары үземне юатам: дәрәҗәле очрашу олыгайган көнгә калган икән. Бик тә күңелебез булып кайттык. Рөстәм белән Гөлсинә тигезлектә генә яши күрсеннәр.

Алар һәркемгә үзләренеке кебек матур гомер тели. Искәндәр абый белән аның егет чакларына кайтып килдек. Үзеннән сигез яшькә кечерәк кызны ничек әләктергәнен дә сораштык.

– Мөслимә апаң минем укучым иде. Армиядән кайткач, күрше Янтуган мәктәбендә укытучы булып эшли башладым. 10 нчыда укыган Мөслимәгә күз төште бит. Берни эшли алмыйм. Гашыйк итте дә куйды. Нәрсәсен яраттың, дисеңме? Тырышлыгына сокландым. Эшкә батыр икәне күренеп торды. Мин аны сынап кына йөрдем, – ди Искәндәр абый. – Мәктәпне бетергәндә, аңа 19 яшь тулмаган иде әле. Миңа инде – 27. Тимерне кызуында суктым, Мөслимәгә өйләндем дә куйдым. Ә ул читтән торып белем алды. Гомере буе мәктәптә математика укытты.

19 яшьлек кыз төп йортка килен булып төшә. Бәхетенә, каенанасыннан да уңа. Мөслимә апаны үз кызыдай кабул итә ул. Бергә 20 ел матур итеп яшиләр, сүзгә килмиләр. Чынлап та эшкә батыр булып чыга килен. Җиде балалы гаиләдә үскәч, әти-әнисе кызларын кечкенәдән эшкә өйрәтеп үстерә.

Бәхетле тормышы өчен 69 яшьлек Мөслимә апа иренә рәхмәтле.

– Мин аның ышыгында гына яшәдем. Аңа бик ышандым. Ул паровоз кебек алдан барды, мин ияреп кенә йөрдем. Бәхетле булуның тагын бер сере – гаиләдә эшне ирнеке, хатынныкына бүлмиләр. Хәтта төнлә бала уянып елаганда, ник тормыйсың син, димәс иде. Үзе уянып, баланы күтәреп, минем янга китереп салыр иде. Иремнән хөрмәт күреп яшәдем. Хатын-кызга тагын ни кирәк соң? – ди Мөслимә апа. – Икебез дә мәктәптә эшләгәч, уртак сүзләр күп булды. Мин тексәм, ул кисеп торды, мин юсам, ирем әлеп барды. Бер-беребездән туйганыбыз булмады.

Алар ике бала үстергән. Уллары Илнар да, оныклары да әби-бабай юлыннан киткән. Барысы да – укытучылар. Ә кызлары Эльвира икътисад өлкәсен сайлаган.

– Аллаһы Тәгалә бездән берни кызганмады. Бәхетле яшәтте. Тиң ярымны дөрес сайладым. Балаларны да тиешле тәрбия биргәнбез. Улыбыз белән килебезне дә 19 яшендә өйләнештеләр. Аларны тугыз ел үзебез белән тоттык. Шөкер, бер-берләрен аңлап, санлап матур яшиләр. Әти-әнигә баласының тормышы түгәрәк булса, шул җитә, – ди Искәндәр абый. – 50 ел күз ачып йомганчы үтте дә китте. Шуңа да гаиләне сакларга тырышыгыз. Күп әйбер ирдән дә тора. Бөтен эшне хатын-кыз җилкәсенә өю дөрес түгел ул. Аңлашып яшәргә кирәк. Хатын-кызга да күп кирәкми – бер сүзең дә җитә кайчак. Шуңа да матур сүзләрне кызганмыйк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

РӨСТӘМ ГАЙЗУЛЛИН: «АКТЕР ҺӨНӘРЕННӘН БАШКАНЫ БЕЛМИМ»

Тинчурин театрының давылы. Замандында режиссер Резеда Гарипова актер Рөстәм ГАЙЗУЛЛИНга әнә шундый бәя биргән иде. Дуамал энергияле актер нинди образда чыкса да, сәхнәне тоту сәләтенә ия. Без аның белән милли кино, театр хәлләре, рольләрнең йогынтысы турында сөйләштек.

:: Кайсын сайлыйсың: киномы, театрмы?
– Ай-һай, андый сайлау мөмкинлеге булырмы икән?.. Булган очракта да, мин театрдан баш тарта алмас идем. 15 яшьтә театр училищесына укырга кердем, шуннан бирле шушы мохиттә кайныйм. Әлбәттә, төрле кызыксынулар булды, алга таба да булыр, әмма төп эш – барыбер театр. Мин әле андый сорау бирсәләр, театр да, кино да, дип җавап бирер идем! Аларның икесендә дә актерлык эше таләп ителә ләбаса. Ике юнәлешнең һәркайсы үзенчә «тәмле». Сәхнәдә образ тудыру бер могҗиза булса, кинода төшү – үзе бер кызыклы процесс.

:: Хәзер безнең үз кинобыз бар, дип әйтә алабызмы инде?
– Ул юнәлештә эш бара. Милли кино сәнгатенең төрле чоры булды, без артист булып өлгергән чорда гына да, аның төрле этапларын күргән, шуларда катнашкан булды. Кино бар, дип күкрәк кагып әйтерлек булмаса да, аның өчен җан атучылар, аны булдырырга тырышучылар бар. Режиссер Илдар Ягъфәров фильмнарын халык яратып карый. Илшат Рәхимбай үзен режиссер буларак таныта. Алар бар, алар күп. Димәк, нәтиҗәсе булачак. Һәрхәлдә, безнең әле үз кинобыз юк, дип әйтә алмыйбыз инде.

:: Театр дигәннән. Тинчурин театрына соңгы вакытта игътибар бик зур. Бу актер иҗатына комачаулыймы?
– Актер ул – башкаручы. Аның язмышы турыдан-туры режиссерга бәйле. Ул сине күрә, синең белән эшли икән, димәк, син уңышта. Әгәр инде рольләр бирелми икән, көтәргә кала. Театрга бәйле вазгыять бөтенләй тәэсир итми дип әйтеп булмый инде, әмма кулдан эш төште, дип зарланырлык та түгел.

:: Рөстәм Гайзуллин дигән актерны ачкан режиссер кем ул?
– Минем остазым – актер, режиссер Илдар Хәйруллин. Шулай ук Тәслимә Хәләф мине актер буларак шомартты. Чөнки уку вакытында тупланган багаж ул – бер нәрсә, тәҗрибә исә – бөтенләй икенче. Бу җәһәттән Кариев театрында Ренат Әюпов кул астында эшләгән вакытны да рәхмәт хисләре белән искә алам. Ә инде иң күп эшләгән режиссер – Рәшит Заһидуллин.

:: Прокурор, подполковник кебек «погонлы» рольләрең күбрәк кебек. Начарларны уйнау җиңелрәкме әллә?
– Бер ябышса, ычкындырмый торган образлар була. Миңа тискәре герой образы ябышкан, һаман җибәрми. Мөгаен, төс-кыяфәтем шуңа туры киләдер. Әлбәттә, башка төрле геройларны да уйнап карыйсы килә. Режиссерларга, мөгаен, миндә калыплашкан образ белән эшлисе җиңелдер, яңадан сүтеп җыярга кирәк түгел бит. Берәр режиссер башка яктан ачып, үземне дә гаҗәпләндерсен иде әле. Сәхнәгә чыгып баскач, тамашачы сине танымаса, менә шул була инде ул эштән кичергән бәхет.

Соңгы рольләргә килгәндә, Туфан Имаметдинов, баш режиссер вазыйфасына керешкәнче үк, «Полиционер» спектаклен куйды, шунда сез әйткән погонлы роль булды. Курсташым Марсель Мәхмүтов «Шах... Мат!» моноспектаклен чыгарды, анда прокурор ролендә идем. Хәер, «Турандык» спектаклендә минем роль тискәре түгел.

:: Рольләр арасында иң якыннары кайсылары?
– Эшли башлаган вакыттан ук алсак, Кариев театрында куелган «Алмачуар» (Галимҗан Ибраһимов) спектаклендәге Закир роле күңелемә хуш килә иде. Туфан Миңнуллин әсәре буенча куелган «Нәзер» спектаклендә Хисмәтулла, кыска гомерле «Соңгы әсәр»дә (Кәрим Тинчуринның автобиографик новелласы буенча) поручик Сәфәрҗанов күңелгә якын. Тугыз ел буе барган «Күрәсем килгән иде» (Исламия Мәхмүтова) спектаклендә Алмаз ролен дә бик яратып уйный идем. «Карурман» да (Луиза Янсуар, Резеда Гарипова) Даян би – иң авыр туган, шуңа бик якын булган рольләрнең берсе.

:: Ә менә «Болгар радиосы»нда иртәнге тапшыруда эшләү театр эшчәнлегенә тискәре тәэсир итмәдеме? Мәсәлән, син җитди роль белән халык каршына чыгып басасың, ә халык танып ала да көлә башлый.
– Театрда 2003 елдан бирде эшлим, ә радио белән 2012 елдан хезмәттәшлек итә башладым. Яшерен-батырын түгел, нәкъ менә радиода эшли башлагач, күбрәк танылу килде. Спектакльне карагач, сезне радио аша белә идек, инде менә килеп күрдек, җитди рольдә күз алдына китерә алмаган идек, дип әйтүчеләр шактый булды. Бу ике юнәлеш бер-берсенә үрелеп тә бармый, комачауламый да. Энергиямне чыгару өчен, аның икесе дә кирәк.

:: Театрга ике бурыч куела: акча эшләү һәм халыкка тәрбия бирү. Бүген беренчесенә күбрәк игътибар бирелә бугай. Димәк, касса спектакльләре алгы планга чыгачак. Бу дөресме, синеңчә?
– Шушы ике юнәлешкә көчләр тигез бүлеп бирелсә, театр алга барачак. Кайсы спектакльнең «кассовый»га әйләнәчәген дә кистереп әйтеп булмый, миңа калса. Классик әсәрне дә шундый итеп куеп була: аңа халык егылып йөрерчәк, заманча әсәрне дә карамаслык итәргә була. Бездә Салават Юзеевның «Кияү урлау» спектаклена халык егылып йөри, мәсәлән. Дөрес, мин үземне театр репертуарына, аның юнәлешенә бәя бирерлек кеше дип санамыйм. Шәхсән үз кичерешләремнән чыгып кына җавап бирә алам. Әйтик, соңгы вакытта традицион театрга каршы чыгалар. Нindидер яңа юнәлеш барлыкка китерү омтылышы бар. Спектакль үк булып җитешмәгән әйберләр, эскизлар, лаборатория җимешләре тамашачыга тәкъдим ителә. Мин аларны начар яки яхшы дип бәяли алмыйм. Тамашачының ниндидер бер өлешенә тәҗрибәләр, лабораторияләр кызыклы булырга мөмкин. Мин исә аларны кабул итеп бетерә алмыйм. Миңа классик әсәрләр күбрәк ошый. Бәлки, ул лабораторияләрдә үзем катнашмаганга, әлеге процессны эченнән өйрәнмәгәнгә кабул итеп бетерә алмыймдыр. «Бу спектакль уңышлы түгел, чөнки мин анда катнашмыйм» дигән мәзәктәгечә булмасын, дим. Менә катнашкач, фикер әйтермен.

:: Театр сезонны «Турандык» спектакле белән ачарга җыена. «Хан кызы Турандык»ны Камал театры да куйды. Алардан соң бу әсәр белән эшләү авыр булмасмы соң?
– Минемчә, төрле режиссерның бер үк әсәр белән эшләп каравы кызыклы. Нәтиҗәдә төрле театрларда бер үк әсәр төрле чишелеш таба. Камал театрының – үз Турандыгы, безнеке исә безнеңчә булачак. Иң мөһиме: яңа чишелеш, яңача караш табарга кирәк. Безнең белән Венгриянең танылган режиссеры, тумышы белән Казан егете Сәрдәр Таһировский эшли. Аның Тинчуринда «Ядәч! Исемдә!» трагикомедиясен куйганы бар. Үзенчәлекле алымнар куллана торган кеше. Тамашачы безнең «Турандык»ка килсә, үкенмәс дип уйлыйм.

:: Гаиләдә ир дә, хатын да бер һөнәр иясе булу комачауламыймы?
– Альбина (Гайзуллина – Карив театры актеры. – **Ред.**) белән безнең актерлык ишек артында кала. Өйдә без ике малайның әти-әнисе, ир белән хатын. Актерны актер гына аңлый дип әйтәләр әйтүен. Без Альбина белән заводта эшләсәк тә, шул ук хәл булыр иде, мөгаен. Чөнки өйдә без нинди бар – шундый. Дөрес, безне театр дөньясы таныштырды. Театр училищесында бер курста укыдык. Димәк, бер-беребезне 1999 елдан бирле беләбез. Өйләнешүебезгә 17 ел булды. Балигълык яшенә чыктык, дип әйтсәк тә була. Гаилә дә кеше тормышы кебек үк этаплардан тора икән. Башта хисләр, дуамаллык алгы планда була. Хәзер инде бер-береңнең кадере арткан чорга кердек. Мин үзем – образларда гына түгел, тормышта да шуграк кеше. 21 яшьтә өйләнештек, бербер артлы ике малай алып кайттык, ә шуклык кимеми, биләмгә чыгып китәсе килә. Хәзер киресенчә, күбрәк өйдә буласы килә, «басынкылык» дигән нәрсә килеп чыкты. Әмма тик торган җирдән кабынып китү, көнчелек өянәге һаман бар. Ул шулай булырга тиештер инде.

:: Әти буларак, тәрбиядә нинди алымнар кулланасың?
– Иң беренче нинди халыктан, нинди нәселдән булуларын төшендерергә кирәк. Безнең балалар татарча сөйләшә, Аллага шөкер. Аннан бер-береңне хөрмәт итү. Әти-әниеңә, туганыңа хөрмәт булырга тиеш. Хөрмәт хисе кечкенәдән сеңдерелсә, ул киләчәктә ярдәм булачак. Аңлашып яшәргә кирәк.

:: Кино дөньясына әйләнеп кайтыйк әле. Заһид Мәхмүди әсәре буенча куелган «Җәза» фильмындагы ролең уңышлы килеп чыккан иде. Соңгы вакытта фильмнарда катнашканың бармы?
– Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» әсәре буенча куелган фильмда катнаштым. Кино – бик кызыклы дөнья ул. Бер татып карадыңмы, һаман кызыктырып, ымсындырып тора.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Блиц-сораштыру:

– Актер булмасаң, нинди һөнәрне сайлаган булыр идең?
– Уйлап караганым да юк. Мин бит хәтта театр училищесына да, керәм, дип бардым. «Керә алмасам...» дигән уй башка килмәде дә. Актер булмасам... Бәлки, шәп пешекче килеп чыгар иде миннән. Ит белән яшелчәләрне шәп пешерәм.
– Иң зур теләк?
– Алар күп һәм үзгәреп торучан. Иң зур теләк дип, бәлки, ике ул, бер кыз үстерү теләк-хыялын әйтеп буладыр. Мин – гаиләдә бер бала, үз балаларыма андый язмыш теләмәдем. Бер бала ул – «псих-одиночка». Бер-бер артлы ике ул алып кайттык, хәзер инде кәбестә арасыннан кыз эзләп йөрмәбез кебек. Кыз урынына Сөембикә атлы мәчебезне тәрбиялибез.
– Кеше холкында иң ошамаган сыйфат?
– Күзгә карап алдалау.
– Иң ошаган сыйфат нинди?
– Кешеләргә ачык йөзле булу.

РҮЗӘЛ МӨХӘММӘТШИН

МИН ДӘ ҮЛӘРМЕН ӘЛЕ...

(ХИКӘЯ)

Рауза карчык Аллаһка минем гөнаһларның кичерелүен сорап ялварды. Авыл зиратындагы барча әрвахларның рух шәрифләренә дога кылды, бабамнарны, әбиләремне, ир һәм кыз туганнарымны исемләп атап, барчасына-барчасына тиге дөньяда оҗмахтан урын сорады. Аннары аңа кучте:

– Ярабби! Рамил улы Раил Фәиз улы Рүзәлне җәдәтеп җөрмәсен, төшләренә кермәсен. Тынычлыкта калдырсын! Әлхәмдүлилләһ.

– Нинди көн җитте бит, Ройка, ә, – дидем мин, үзем ишетерлек кенә. – Безне Аллаһка исем-отчестволап таныштыралар...

Үлеменнән соң берничә көн үтүгә Ройка тәүге мәртәбә төшемә керде. Төше дә әллә ни түгел иде, җитмәсә, үзем дә хорафатларга артык ышанмыйм – кыскасы, ул төндә күргәннәр миңа берничек тәэсир итмәде.

Шулай да...

Мәктәп еллары, имеш...

Без – Ройка, Рафил, мин – ни сәбәпледер Кәркәвеч клубына төшкәнбез. Мин анда гомер булган кеше түгел югыйсә. Нишләптер, һәммәбез дә авылча киенмәрдән: Ройка бейсболка, совет заманындагы мәктәп формасын кигән. Шулай йөри иде ул... Мәйдан шаулый, яна! Баштан ары сикермәкче булабыз. И бии Рафил! Хәер, Рафил, дим әле... Һичкайчан бии белмәгән үзем дә шатыр-шотыр җилдерәм генә! Аяклар җиргә тими. Ә Ройка моңсу менә. Йә тавыш-тынсыз басып тора, йә дивар буйлап тезелгән урындыкларның берәрсенә барып утыра.

Мин түзмәдем – якасыннан тотып, җилтерәттем аны:

– Уян, әйдә! Нигә моңсуланасың, шап бит! Әйдә, кушыл, – дидем.

– Юк, – дип баш тартты ул. Дәшми генә чыгып та китте. Шау-шу аша да ишекнең шап итеп ябылганын аермачык ишеттем. Музыка көчәйде (билләһи, Шекспир трагедиясе, диярсең: музыка көчәя. Ут сүнә. Пәрдә). Ройканың юкка чыгуын һичкем сизмәде.

Рафил белән без дә биеп калдык.

Ройка китте, ә без биеп калдык.

Без һаман биибез әле...

Ул ике дөнья чиген кичкәндә, мин Казанда идем.

Милли музейда лекцияләр тыңлаган чакка туры килде.

Бина эчендә кызу иде. Чәч арасында бөрчек-бөрчек тир шытып, әледән-әле маңгайдан, ияктән ага торды...

Кесәдә бырылдаган телефон мине сискәндереп җибәрде. Кайсы хәерсезе икән? Телефонны кулга алдым. Укыдым: «Раил үлгән». Мин, дөрес күрмәдем, ахры, дип, күзләремне тагын берничә мәртәбә электрон хәрефләр буенча йөгерттем. Нәрсә бу?

Калтырый-калтырый, смс җибәргән номерны – сеңлемне кире җыйдым:

– Ни яздың син?

– Абый, Раил үлгән.

Мин тораташтай каттым. Сүгенеп куйдым.

– Ничек? Кайда?

– Казансуда баткан...

– Ой-йо.

Шул сүзләрдә элемтә өзелде.

Бетте. Минем өчен лекция, алай гына да түгел – бу көн, бәлки, аннан да күбрәге – тәмам иде. Дәфтәр-ручканы пакетка аткарып, урамга чыктым. Биредә тагын да тынчу иде. Кремль урамыннан университетка таба атладым, ләкин озак бара алмадым – аяклар чуала башлады. Бераздан туктап, аркам белән йорт диварына терәлдем, аның буенча шуып төшеп, чирәмгә чүгәләдем. Янәшәмнән генә миңа һәм, гомумән, бөтен дөньяга битараф булган адәмнәр уза торды. Кайберләре шикләнеп карады, кайберләре көлде. Аларга ни ул – таныш түгел егетнең баш иеп утыруы? Мин күзләремне күккә төбәдем: зәңгәр-зәңгәр болытлар да каядыр ашыга иде. Тамак кипте, кармакка эләгеп, яр кырыена ыргытылган балык төсле, мин авызымны ачтым, һаваны йоттым – гүя бу һава минем сусавымны басарга мөмкин иде...

Ройка үлгән. Ройка үлгән... Ройка үлгән!

Сеңлем әйткән сүзләр минем башымны ярды, контузияләнгән хәрби кебек, колагымда бары тик шушы хәбәр генә яңгырады:

– Ройка үлгән!

Ничек инде алай, ничек инде...

Ничек инде?!

Әле генә Сабан туенда бергә йөргән идек бит...

Ройка безнең өйдә утыра, имеш.

Мин аның үле икәнен беләм. Ләкин ул, ничектер, кире кайткан. Иң кызыгы: үзе берминди хис тә, тәм-ис тә тоярга сәләтсез. Без икәү кече якта. Табын тулы сый-нигъмәт, чәй эчәбез...

– Ипи тәме дә юкмы авызыңда? – дип сорыйм.

Яшәргә ияләнеп беткәндә генә – китәргә кирәк!

Сабан туенда бик моңсу йөрде ул...

Ройканы әйтәм.

Юк, үләчәген алдан сизенгәндәй, моңсу йөрде, димим. Алай булмагандыр. Кем үзенең үләчәген алдан белсен инде?

Сабан туе мәйданы клуб каршында гына. Мәйданда көрәшкәне көрәшә, көч сынаша, көрәшмәгәне тал-тирәк куләгәсендә аракы эчә... Хәер, алай дисәң, тегесе дә, бусы да көчен сыный инде.

Мин ни эшләргә белми аптырап йөрим. Таныш-белешләр күп, ә кирәк кеше – юк дәрәҗәсендә. Булганы да йә парлашып (егет белән кыз) узып китә, йә балалары белән туңдырма алырга чират тора. Кыскасы, Башлачевның бер җырындагы кебек, «сплошной духовный неуют...»

Уемны укыгандай, тузан туздырып, шәмәхә-зәңгәр ВАЗ 2106 яныма килеп туктады. Эчтә Федя белән Рустик иде. Федя вәкарь генә машина ишеген япты да мине кочып алды:

– Юк, – ди ул миңа, моңсу елмаеп.

– Исен дә сизмисеңме?

Аны ымсындырыр өчен иснәп күрсәтәм.

– Юк, – ди ул.

Без урамга чыгып китәбез. Чиләкләп-чиләкләп яңгыр ява. Мин, исәрләнгән сыман, кулларымны як-якка җәеп, яңгырны кочмакчы булам. Эре-эре тамчылар минем чәчләремне, йөземне чылата, иңбашларым буйлап аяк очларыма агып төшә. Миңа шулкадәр рәхәт, рәхәт, нигәдер!

– Яңгырны да сизмисеңме? – дим.

Ройка баш кага. Үзе гаять, гаять моңсу инде!..

Мин уянып киттем. Караватка утырдым да уйга калдым. Нәрсә бу? Төшем күптән түгел караган кинофильмны хәтерләтә иде. Николас Кейдж персонажы (төшемдә Ройка башкарды бу рольне) – кешенең гомерен алучы фәрештә. Кем артыннан килсә, шуның гына күзенә күренә. Шулай ук ис тә сизми, тәм дә тоймый – һәммә хисләрдән мәхрүм. Әмма мәңгелек.

Ройка шушы фәрештә булып яныма килгәнмени?

Мин бу төшне беркемгә дә сөйләмәдем. Курыктым. Үзем сабыр гына гомеремә нәтиҗәләр ясап карадым...

Иртә әле! Ай-һай, иртә!

Берни эшләргә өлгермәдем ләбаса! Китәсе килми икән әле!

Хәер, беркайчан да китәсе килмидер ул. Туган авылыңа кайтып, озаграк торгач та, әти-әниеңнән, чишмә-тугайларыңнан, тау-елгаларыңнан аерыла алмый интегәсең: китәсе килми! Ә монда егерме ел (ни дисәң дә, каникулга кайтудан күбрәк бит!) яшәгәннән соң кинәт кенә ишек шакысыннар да, автобус көтә, тизрәк җыенырга кирәк, дисеннәр, имеш...

Ләкин дөньяда озаграк торган саен китәсе килмәү тәләге дә көчәя бара, чөнки озаккарак сузылган һәр мизгел, һәр көн, һәр ел китәргә кирәк булган вакытны якынайта.

– Нихәл, брат?

– Ярый.

– Әйдә, бик скушныга охшаган монда, киттек, Өшенгә төшәбез...

Рустик күбрәк урысча сөйләшә. Шуңа күрә, барыбер аңламам, дипме, әңгәмәгә кушылмый. Гәрчә машина аныкы һәм йөртүче ул булса да.

– Әйдә, – дидем мин. – Кемнәр төшә соң?

– Син, мин, Рөстәм.

Рөстәм – шул ук Рустик инде.

Ул арада әллә кайдан Салават килеп чыкты, аның да Шөн һавасын сулыйсы килә икән. Минем яңа гына бу тирәдә Ройкага юлыгуым искә төште. Сөйгәнен дә иярткән иде әле. Әһә... Әнә ул.

– Киттек, – диде Ройка, битараф кына.

– Бызгыштыгызмы әллә?

– Юк, нормально.

Шулай да, ызгышканнар бугай. Юкса, болай тиз ризалашыр идеме?

Киттек.

Юл озын түгел. Шөн дигәнебез – күрше авыл гына. Дөрес, бу якта асфальтның әсәре дә юк. Тузан иснәп барасы. Бер рәхәтнең бер михнәте – түзәсең инде.

Ройка пистолет чыгарды.

– Син нәрсә?! – дидем мин, каушап.

– Хәзер моннан башка йөрмим. Казанда тотып типкәләделәр...

Пистолеты – пневматика гына югыйсә.

– Кемнәр типкәләде? – димен.

– А хрен их знает!

Мин Ройкага күз ташладым: битендә бер-ике чи яра бар иде шул...

– Пычак беләнме? – дип шуларга ымладым.

– Кастет.

Бераздан рульгә Федя утырды. Әле «права» алып өлгермәгәнгә, уңай форсатны кулдан ычкындырасы килмәде аның: басу таптап кына салынган юлда данлыклы һәм гадел гаишниклар очрамаячагы көн кебек ачык иде.

Ә көн ачык иде, чыннан да.

Дәвамы бар >

Халисә ШИРМӘН

***

Кемнеңдер бәхете булырсың.
Син – минем укылган китабым.
Ачамын тын гына битләрен,
Барлыйммын тормышым этабын –

Бары да, барсы да урынында!
Очрашу-кавышу көннәре...
Яхшысы, татлысы уйларның –
Мәхәббәт булганга әлгәре...

Аннан соң... ераграк посканнар
Нахакка сибелгән рәнҗешләр...
Син әйткән, мин әйткән авыр сүз
Хәтердә калмаска тиешләр.

Кадерле, иң якты мизгелләр
Күңелем түрендә сакланыр.
Саклаңыр! Тик алар яңадан
Кузгатмас күңелем кылларын.

...Тын гына моң ява юлларга.
Борылып карама артыңа:
Без йөргән сукмакта – башкалар...
Китәм мин...
Мин китәм – яктыга!

***

Җылы көтә күңелем... Син иренмә,
Чык та бүген урам чатына
Алып керче миңа яз сулышын,
Матур сүз әйт сөю хакына –

Диген: «Котлыйм, бәгърем! Бүген бәйрәм!
Хатын-кызлар көне дөньяда!
Син – чәчәгем минем тормышымда!
Яшәү ямьле тик син булганда!»

А́лда әле шулай... Ә мин ышанырмын,
Елмаермын синең сүзеңә.
Хатын-кызга тагы ни кирәк соң?!
Шатлык кунар сулган йөземә –

«Иң ягымлы ир-ат – син ул!» – диеп,
Баш салырмын таныш иңнәргә.
А́лда әле, бәгърем! Алданырмын!
Алданасым килгән көннәрдә

«Мин бәхетле!» – диеп юанырмын.
Лалә чәчәкләре кызарыр –
Матур ялган бизәр тормышымны.
Яшәү көче алга юл ярыр...

...Җылы эзли күңел. Җылы эзли!
Матур сүзләр бүген коела.
Һәр ялганга күңел җавап бирә –
Дөнья матур... Матур тоела!

***

Бармагың ак алтын балдаклы –
Чәчләрең чәчләргә бәйләнгән.
Нигә соң, күз атып ятларга,
Тормышың ялганга әйләнгән?

Хәләлең зарыгып көткәндә,
Син ятлар куенында эрисең.
Сөюнең кайнарын, көчлесен,
Ай саен яңасын телисең...

Ни эзләп карыйсың, елмаеп,
Җавапка елмайган күзләргә?
Юк анда җылылык... Юк анда ярату...
Тик томан урала сүзләргә...

Беләсең, бер көнлек хисләрдән
Үзең дә туйгансың... Аргансың.
Таптаудан чит-ятның тупсасын
Ниндидер юаныч табасың...

Хәләлгә хисләрең суынган...
Үкенеч йөртәсең җаныңда.
Күзләрең күтәреп карарга
Бик авыр...
Бик авыр аңа да...

...Бармагың ак алтын балдаклы –
Бердәнбер барыбер сөйгәнең...
Челтәргә әйләнә күңеле
Кешедән кешегә йөргәннең...

ЯЛДАН СОҢ БЕРЕНЧЕ ЭШ КӨНЕ

Хак лайфхак!

Ну нәрсә, егетләр-кызлар, ял итеп булдымы? 1 сентябрь житү белән, балаларның каникулы да, ата-аналарның отпускы да тәмамлана. Ялдан соң беренче эш көне адәм баласы өчен бик стрессы булырга мөмкин, ди психологлар. Һәм үз киңәшләрен бирәләр.

- Беренче эш көнендә авыр эшләр алмагыз. Вакытыгызны күбрәк эшне планлаштыруга юнәлтегез.
- Эш өстәлегездә тәртип ясагыз, документларыгызны төрле папкаларга бүлегез.
- Өегездән күзне ял иттерә торган әйбер алып килегез. Әйтик, балаларыгызның фотосы, яраткан гөл һ.б.
- Төшке аш вакытында урамга чыгып, парктан әйләнеп керү файдага булыр.
- Төшке ашны якын-тирә кафеда ашау күңелегезне күтәрер.
- Хезмәттәшләрегез белән низагка кермәгез. Низаг чыга башласа, аны шаяруга борыгыз.
- Ярты сәгать саен урыныгыздан торып, гимнастика ясап алу мәслихәт.
- Эштән вакытында китегез. Беренче көнне үк калып эшләмәгез.
- Өйгә гадәти юлдан түгел, ә башка юлдан кайтыгыз.
- Һәм, иң мөһиме, шуны онытмагыз: чираттагы отпускыга кадәр нибары 11 ай калды!))

Әз-мәз мәзәк

* * *

Август ахыры ул якшәмбе киче сыман.

* * *

Мин эшемне яратам да бит, хезмәт хакым мине яратмый шул.

* * *

Сиңа кызың җибәргән җырны тыңларга гына түгел, аны анализларга кирәк.

* * *

Ире эшеннән бик соң кайта. Аны уклау тоткан хатыны каршы ала.

– Матурым, күпме әйтергә була сиңа: мин икенче сменада эшлим!

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Имәнкискә, Карчыга, Нәсим, уйнаш, ул, Мостафа, Адымнар, чама, он, Вәлиев, урман, дары, Мане, хейт, төр, шоссе, Ур, Тогар, тире, Кпалиме, как, Уфа, Ганс, әти, гөл, Ут, бетчә, тегермән, Тәслимә.

Вертикаль: Ибраһимов, хоккейчы, сөләйман, Ален, тир, Том, Сандугач, дөге, Мәгубә, ара, төтен, Әхсән, Амур, Рафаил, аударыш, Камышлы, Ока, Зөлфәт, Миасс, Ка, Метан, Роза, икс, Нур, Апанаев, терекөмеш.



Беләсең килсә...

1 Күренекле хәрби, армия генералы, тарих һәм хәрби фәннәр докторы, профессор Мәхмүт Гәрәев кайсы шәһәрдә туган?
а) Казан;
б) Оренбург;
в) Чиләбе.

2 Кытайда бу төс кайгы һәм матәм төсе булып санала:
а) кызыл;
б) ак;
в) сары.

3 Үзен «беренче татар блогеры» дип атаучы егетнең чын исеме:
а) Ринат Габидуллин;
б) Ринат Галиәхмәтов;
в) Ринат Тажетдинов.

4 Японияда фил кәкәйләреннән ясалган нәрсә бар?
а) сыр;
б) сыра;
в) шәраб.

Җаваплар: 1-в). 2-б). 3-б). 4-б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 312

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булырак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәширят комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+